БУЛГАНДА АЛЫРГА

Татарстанда ит дефициты булу дәреслеккә туры киләме?

> 6

БӘХЕТЛЕ НАЛАСА

Элеккеге миллионер колхозда бүген дә халык муллыкка омтылып, бәрәкәткә ирешеп яши

> 16

ПРЕМИЯ ЯРМИНКӘСЕ

Бер караганда, ул матди ярдәм кебек бирелүдән туктарга тиеш иде...

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 45 (28818) | Җомга | 1 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«ВТ» архивыннан

МҮКЛӘҮДӘН БИГРӘК ЧУТЛЫЙСЫ

РОССИЯДӘ ТӨЗЕЛЕШ МАТЕРИАЛЛАРЫ АРЗАНАЙГАН

Бар нәрсәгә бәя котырып үскән көннәрдә күңел җылытырлык хәбәр ишетелде. Россиядә төзелеш материаллары очсызланган. Төзелеш материаллары кибетенә эзне суытмаган күпләр җиңел сулап куйгандыр. Юклы-барлы акчага өч бәягә материал алып йорт җиткезү ай-һай авыр шул. Әмма «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән белгечләр төзелеш материаллары очсызлануны вакытлы күренеш дип саный. Шуңа күрә мөмкинлеге булган кешегә төзелеш кирәк-яракларын бүген алып калырга киңәш итә алар.

> 5

Ишетми калмагыз

Язгы чакырылыш башлана

Владимир Путин хәрби хезмәткә язгы чакырылыш турында указга кул куйган. Документ хокукый мәгълүматлар рәсми сайтында басылып чыкты. Указда күрсәтелгәнчә, 1 апрельдән 15 июльгә кадәр 18дән 27 яшькә кадәрге егетләр хәрби хезмәткә чакырылачак. Тәгаенләп әйткәндә, 134500 кеше армиягә китәчәк. Моннан тыш дәүләт башлыгы чакырылыш буенча хезмәтен тәгәлләүчеләрне хәрби хезмәттән азат итү турында карарны имзалаган.

Моңа кадәр оборона министры Сергей Шойгу белдергәнчә, быел язын хәрби хезмәткә чакырылучылар саны узган елдагыдан кимрәк. Егетләрнең берсе дә «кайнар нокта»ларга җибәрелмәячәк.

Кешедән күп машина

Казан иң күп машинага ия булган Россия шәһәрләре арасында бишенче урынга чыккан. «Автостат Инфо» порталында хәбәр ителгәнчә, 2021 елның декабренә Татарстан башкаласында автомобильләр саны 396,3 меңгә җиткән. Рейтингта Мәскәү беренче урында бара: анда 3,9 миллион «корыч ат» (илдәге барлык автомобильләрнең 8,87 проценты) исәпләнә. Ел башына илдә барлыгы 44,04 миллион җиңел машина теркәлгән.

Икенче урында – Санкт-Петербург (1,67 млн). Екатеринбург (500,3 мең) – өченче, Новосибирск (456 мең) – дүртенче.

Сөенечле хәбәр!

4–14 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**

гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**

гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+

ТАТАРСТАННЫКЫ КИРӘК

Президент көндәлеге

Дубайдан – Сенегалга. Бу көннәрдә Татарстан Президенты эш сәфәре белән Көнбатыш Африка дәүләтендә. Биредә ул «Татарстан – Сенегал» форумында катнашты, кайбер тармаклар буенча эшлекле юнәлешләрне барлады.

tatarstan.ru

Татарстан һәм Сенегалның машина төзелеше, нефть химиясе, авыл хуҗалыгы һәм инновацияләр өлкәсендә хезмәттәшлек итү мөмкинлекләре зур. Форум кысасында узган «түгәрәк өстәл»дә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шул хакта белдерде. Аның сүзләренчә, Африка дәүләтенә эш сәфәре белән килүнең максаты да – яңа сәүдә-икътисади хезмәттәшлек мөмкинлекләрен киңәйтү һәм эшлекле элемтәләр урнаштыру. Сүз уңаеннан, Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясендә республиканың сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримов, «Татнефть» генераль директоры Наил Мәгановн, «Ак Барс» компаниясе генераль директоры Иван Егоров, «КамАЗ», «Казан вертолет заводы», «Ремдизель» җәмгыяте вәкилләре дә бар.

Республика җитәкчесе әйтүенчә, 2021 елгы товар әйләнешенең санлы нәтиҗәләре 1,76 млн долларны тәшкил иткән. 2003 елдан башлап Сенегалга 167 берәмлек «КамАЗ» техникасы җибәрелгән. Шулай ук Сенегалдагы машина йөртүче һәм механиклар өчен махсус өйрәтүләр оештырылган.

Форум кысасында Татарстан Президенты Гамбия вәкилләре белән дә очрашты. Россиянең эре сәнәгать үзәге булып торган Татарстан белән аларның да элемтәләр булдырасы килә. Аларны нефть тармагы, Татарстанда җитештерелә торган товарлар импорты, ашламалар китертү тармагы кызыксындырды.

Рөстәм Миңнеханов бу җәһәттән:

– Без Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре белән тыгыз эшлибез. Илебез Президенты Владимир Путин да моңа зур игътибар бирә. Аның кушуы буенча «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзәтчелек төркемен җитәклим. Анда сездән вәкил кертү мәсьәләсен карарга әзербез, – диде.

Татарстан Президенты Гамбия вәкилләрен республикага кунакка да дәште.

– Май аенда Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Аның кысасында «KazanSummit» икътисади форумын оештырачакбыз, сезне дә катнашырга чакырабыз, – диде ул.

Ветераннар медаль алды

Дәүләт Советында парламент ветераннарына «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медален тапшыру тантанасы үтте. Республика Президенты Указы нигезендә, республиканың социаль-икътисади мөмкинлекләрен үстерүгә зур өлеш керткән өчен элеккеге 23 депутат һәм Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәре әлеге медальгә лаек булган.

«Сез озак еллар буе Татарстанны, хакимиятнең вәкиллеке органын үстерү хакына хезмәт куйдыгыз, – дип мөрәҗәгать итте бүләкләнүчеләргә парламент башлыгы. – Татарстан үз Конституциясен эшләүгә керешкән генә елларда социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең нинди булганлыгын барыбыз да яхшы хәтерлибез. Ул чагында нәкъ менә сез республиканың Төп Законын булдыруның чишмә башында тордыгыз».

Аерым алганда, дәүләт бүләген IV чакырылыш депутаты Виктор Бударин, III чакырылыш Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары Галина Фәхретдинова, Дәүләт Советы Аппаратының элекке хезмәткәрләре – Җәмил Мөхәммәтов, Александр Назаров, Татьяна Гусева, Нурия Хәйруллина, Владимир Устин һәм Эльмира Ошинага тапшырдылар.

ИСТӘ КАЛЫРЛЫК БУЛСЫН

Казанда «Бердәм Россия» партиясе Татарстандагы төбәк бүлегенең илкүләм проектларны тормышка ашыруда һәм алар турында мәгълүмат җиткерүдә ярдәм итү мәсьәләләре буенча комиссиясе утырышы узды. Чара барышында «Илкүләм проектлар: Татарстан – 2021» республика фотосурәтләр бәйгесенә йомгак ясалды.

tatarstan.ru

Җиңүчеләргә бүләкләрне Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды. «Илкүләм проектлар социаль инфраструктураны һәм халыкның тормыш сыйфатын яхшырту буенча масштаблы программа булды», – диде ул. Парламент башлыгы искәртеп үткәнчә, узган елда Татарстан 12 илкүләм проектта (аңа 46 төбәк проекты кергән) катнашкан. Программаларны гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан, шулай ук республика бюджетыннан барлыгы 34,1 миллиард сум булеп бирелгән.

2021 елда илкүләм проектлар буенча Татарстанда 3 мәктәп һәм 16 балалар бакчасы, Кукмарада спорт залы, Казанда спорт комплексы, Алексеевск районында өсте ябылы шугалак, 57 авылда мәдәният йорты, Алабуга һәм Яшел Үзәндә 2 мәдәният үзәге төзелгән. Моннан тыш авария хәлендәге 352 фатирдан яшәүчеләрне яңа торакка күчерүгә, 57 парк-скверны төзекләндерүгә, чистарту корылмаларын һәм су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләүгә, өч чүплекне чистартуга ирешелгән. Төбәк проектлары кысаларында барлыгы 555 объект төзелгән һәм ремонтланган.

«Партия әгъзалары яңа җирле проектлар тәкъдим итә, бу эшкә хәйриячеләрне җәлеп итә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Мәсәлән, «Демография» илкүләм проекты кысасында гериатрия бүлмәләре булдыру эше дәвам иттерелә. Мәгариф оешмаларында 1000нән артык шахмат зонасы булдырылды. Бу эштә депутатлар, предприятиеләр җитәкчеләре, коммерциясез оешмалар, гади халык катнаша».

Моннан тыш, быел мәгариф учреждениеләрен капиталь ремонтлау буенча махсус проект старт ала. Аның кысасында яңа уку елына республиканың 66 мәктәбен ремонтлау һәм җиһазлау планлаштырыла, бу максатларга 3,8 млрд сум чамасы акча тотылачак.

Узган елда «Илкүләм проектлар: Татарстан – 2021» республика фотосурәтләр бәйгесенә барлык муниципаль берәмлекләрдән һәм министрлыклардан 2,5 меңнән артык эш кабул ителгән. Фотолардан тыш, быел конкурска беренче тапкыр видеороликлар кабул ителде. Бүләкләр Татарстан районнарында илкүләм проектларны гамәлгә ашыру турында иң яхшы видеороликлар өчен муниципаль берәмлекләрдәге комиссия җитәкчеләренә тапшырылды. Биектау, Чүпрәле, Әлмәт районнары җитәкчеләре, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе, шулай ук авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры гран-приága лаек булды.

ӘЙТҮ – БЕР, ЭШЛӘҮ БАШКА

Закон бар, һәркем үз вазыйфасын белә, тулы көчкә эшләүче генә юк. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин Хөкүмәт йортында Татарстанда телләр турындагы законны гамәлгә ашыру буенча совет утырышын үткәрде. Әлеге закон ни дәрәҗәдә үтәлә? Җитешсезлекләребез күбрәкме, уңышларыбызмы?

2021 ел нәтиҗәләре белән Татарстанның юстиция министры Рөстәм Заһидуллин таныштырды. Министр сүзләренчә, татар һәм рус телләрен тигез файдалану шарт булган кайбер өлкәләрдә уңай үзгәрешләр күзәтелә. «Әйтик, 2018 елда норматив актларның татар һәм рус телләрендә тигез дәрәҗәдә бастырылуы 79 процентны тәшкил иткән булса, 2021 елда әлеге күрсәткеч 99,3 процентка җитте. Шушы ук вакыт аралыгында сайтларда татарча хәбәрләр урнаштыру күрсәткечләре дә 97 проценттан 100 процентка кадәр артты», – диде ул.

Ләкин барысы да ал да гөл түгел шул. Хакимият органнары һәм район сайтларында татарча мәгълүматның аз булуы, яңалыкларның соңга калып тәрҗемә ителүе – җитешсезлекләрнең берничәсе генә. «Сайтларда орфографик, лексик, логик хаталар да гаять күп. Шунлыктан балыклар – кешегә, бәкеләр – куышка, районнар оҗмахка әйләнә», – диде министр.

Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни эшләр буенча директор урынбасары Олег Хисамов исә, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарында эшләү өчен тәрҗемәчеләр әзерләү системасын камилләштерергә кирәклеген белдерде. «Районнарда мондый кадрлар булдырылуга карамастан, безнең институтка мөрәҗәгатьләр саны кимемәде. Без республика һәм муниципаль бюджет акчасы хисабына әзерләнә торган социаль реклама, мәгълүмат баннерлары, стендлар һәм башка визуаль мәгълүмат чараларына игътибарны арттырырга тиеш, чөнки дәүләтнең бу өлкәдәге сәясәтен нәкъ менә алар чагылдыра», – диде ул.

Стенага борчак сибүне туктатырга кирәк. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин телләр турындагы законның үтәлешеннән риза булмавын әйтте.

– Башкарма хакимият органнары – өч, ә җирле үзидарә органнары биш күрсәткеч буенча планны үтәмәгән. Быел гына түгел, бу хәл инде 2019 елдан бирле кабатлана. Дәүләт телләре турында республика законы бар – аны бары тик үтәргә генә кирәк. Ә үтәр өчен эшләү зарур. Моңа игътибар итүегезне һәм бу юнәлештә эшне көчәйтүегезне үтенәм, – диде ул, утырышка нәтиҗә ясап.

Песошин Татарстан Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразыевка әлеге проблемаларга ачыклык кертергә кушты. «Эше булгач, нәтиҗәсе дә булсын. Кирәк булса, бер айдан тагын очрашырбыз», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ДАВЫЛ УЗГАЧ, КЕМ КАЛЫР?

Без билгесезлектә. IT-тармак белгечләре бер авыздан шундый зарын җиткерде. Фикерләрен, сорауларын ишетүчеләр булды үзе. Шунысы хак: барыбыз да цифрлы өлкәгә нык бәйле икән.

«Штаб» үзәгендә җитәкчелек, бизнес вәкилләре, яшьләр, студентлар, мәгълүмати технологияләр тармагы белгечләре катнашында очрашу узды. Барысы да чараның «Давылны ничек кичәргә һәм IT-тармакта алдынгылыкны саклап калырга?» дигән төп соравына җавап эзләде. Шунысын да әйтергә кирәк: әлеге чара Kazan Digital Week халыкара форумы кысасында оештырылды.

Сүз уңаеннан, «ПромРейтинг» тикшерүләр агентлыгы Татарстан халкының цифрлаштыруга карата мөнәсәбәтен сорашкан. Сораштыруда катнашканнарның яртысы диярлек каршы килмәвен әйткән. 26,6 проценты тискәре мөнәсәбәттә икән. Иң күбе – хатын-кызлар. Гаҗәпләндерерлек түгел: цифрлаштыруга 14–17 яшьлек яшүсмерләр һәм 18–24 яшь аралыгындагылар хәерхаһлы.

Цифрлаштыруның уңай якларын күбрәк кайсы өлкәләрдә тойганнар соң? Сораштыруда катнашучылар әйтүенчә, «Дәүләт хезмәтләре» порталы, интернет элемтә, банк, навигация һәм транспорт тармакларында замана технологияләрен куллану яхшы. Бу чиратлар кимүгә, теге яисә бу хезмәт өчен күп вакыт сарыф итмәскә мөмкинлек бирә, тизлеккә һәм сыйфатка тәэсир итә. Цифрлаштыруның куркыныч күренешләренә килгәндә, шәхси мәгълүматның таралуы, җәмгыятьтәге контроль көчәюне атаганнар.

Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе советы рәисе Рифкать Миңнеханов та мәгълүмати технологияләрнең хәзерге көнкүрешебезгә ныклап үтеп керүен искәртте. Шуның бер мисалы – «акыллы» транспорт системалары (ИТС. – **Ред.**). Гадиләштереп әйткәндә, камера, фотофиксация һәм машина хуҗалары бик үк яратып бетермәгән башка алымнар ул.

– Сораштырулар күрсәткәнчә, халыкның 40 проценты гына фотофиксациянең куркынычсызлыгын билгеләп үтә, 60 проценты башка фикердә. Менә мисал: 2004 елда Татарстанда юл-транспорт һәлакәтләрендә үлүчеләр саны 882 иде, ә 2021 елда – 231. Кем генә, ни генә дисә дә, үлүчеләр саны кими, – дип, замана технологиясенең уңай ягына басым ясады Рифкать Миңнеханов.

Яңа технологияләрнең көнкүрешебездә тиз арада үзләштерелүе – бер хәл, ә ул акыллы идеяләрне җиткереп торган акыллы башлар калмаса? Хәзер, мәсәлән, IT-тармак белгечләрен (бигрәк тә яшьләрен!) илдә калдыру өчен аеруча тырышалар. Соңгарак калмадыкмы дигән шик тә бар.

Әмма киткәннәрнең кайтасы да килә икән. «Иннополис» махсус икътисади зонасы генераль директоры Ренат Хәли-

tatarstan.ru

мов шулай дип ышандырды. Китү турында карарны күпчелеге кызган баштан, хисләргә бирелеп кенә кабул итүе ихтимал бит. Һәрхәлдә, моңа безнең дә, Ренат Хәлимовның да ышануы зурдан.

– Иннополиска барыннан да бигрәк Мәскәүдән кайтып төпләнәләр. Бигрәк тә пандемия чорында таш каладан шәһәр читендә уңайлы шәһәрчеккә агыла башладылар. Кул сузымында гына мәктәбе, кибете, ерак йөрисе юк – урманы, чаңгы шуу базасы, башкасы бар бит. Иннополистагы компания хезмәткәрләренең 80 проценты – Россиянең 55 төбәгеннән күченеп кайткан кешеләр, – диде җитәкче. – Хәзерге вакытта республикада IT-тармак белгечләренең күпләп китүе күзәтелми. Соңгы мәгълүматлар буенча, 2 проценттан кимрәге генә башка җиргә күченгән. Минемчә, күченү турында карарны күпләр хисләргә бирелгән вакытында кабул итә. Әле менә өч кеше белән аралаштым. Кайтырга телиләр.

Кызыксындыра торган шартлары бар чөнки. Ренат Хәлимов әйтүенчә, бердән, IT-белгечләр балаларының Россия мәктәпләрендә укуларын тели. Икенчедән, читтә торак бәяләре дә сизелерлек арткан. Кайсыларында Россия кешеләренә тискәре мөнәсәбәт белән очрашырга туры килә.

Рифкать Миңнеханов исә дәүләт тәкъдим иткән ярдәм чараларыннан мөмкин булганча файдаланып калырга чакырды. Федераль акча юкка бирелми, аны дөрес итеп куллана белергә генә кирәк, дигән фикердә җитәкче. Гомумән, кризис дип кул кушырып утырырга кирәкми дә икән. Бер ишек ябыла икән, икенчесе ачыла. «Чикләү – ул әле мөмкинлекләр вакыты да» дигән сүзләр бер генә яңгырамады бу очрашуда. Ренат Хәлимов әйтүенчә, илнең икътисад мәйданыннан киткән компания-оешмалар Россиянең «йомшак» урыннарын күрергә ярдәм иткән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Айдар ШӘЙХИН

Һәр / һич / бер

Һәрхәлдәме, һәр хәлдәме? Һәрвакытмы, һәр вакытмы? Мондый сүзләрдә еш буталабыз, кагыйдәсе бар: беренче өлеше *һәр*, *һич* һәм *бер* сүзләре булган, икенче өлешендә сорау алмашлыклары булган алмашлыклар һәрвакыт кушылып языла: *һәркайда, һәркайсы, һәркайчан, һәркем, һәрнәрсә, һичайда, һичкайсы, һичкайчан, һичкем, һичнәрсә, беркайда, беркайсы һ.б.*

Шул ук принципка таянып кушылып языла: *һәрхәлдә, һәрдаим, һәрвакыт, һәртөрле һ.б.*

ЗЫЯН КҮРҮЧЕЛӘР

Сәхифәбезгә мөрәҗәгать иткән газета укучыларның берсе менә нинди җөмләгә игътибарыбызны юнәлтте: *«Казанда шәхси йортта янгын чыккан, зыян күрүчеләр юк»*.

Әлеге җөмләдә хата юк та сыман. Шулай да, *зыян күрүчеләр* сүзтезмәсенә игътибар итәргә кирәк.

Эш шунда ки, янгын, юл һәлакәте һәм башка күңелсез вакыйгаларда, кагыйдә буларак, зыян күрүче кешеләр булмый калмый. Әйтик, йортта янгын чыгып, анда зыян күрүче юк икән, димәк, йорт беркемнеке дә булмаган, аның яну-янмавына бөтен кеше битараф. Чынлыкта, әлбәттә, зыян күрүче бар: йортның хуҗасының сәламәтлегенә зарар килмәсә дә, матди яктан ул һичшиксез авырлык кичерә (иминиятләштерү компаниясен алдарга ниятләгән булмаса инде, әлбәттә).

Мондый очракта *зыян күрүчеләр юк* дип әйтү мәгънәви хата булачак дип саныйм. Шуңа күрә, әгәр дә табиб ярдәменә мохтаҗлык кичермәсәләр, *сәламәтлегенә зыян килүчеләр юк* яки *яраланучылар, һәлак булучылар юк* дип язарга тәкъдим итәм.

ТЕЛЕГРАМ КАНАЛ

Илдә Facebook һәм Instagram томалангач, күпләр «ВКонтакте», «Одноклассники» социаль челтәрләренә һәм «Телеграм» мессенджерына кайтты яисә күчте. «Телеграм» аеруча зур үсеш кичерде, чөнки күп кенә оешмалар һәм кызыклы шәхесләр анда үз каналларын булдырды. Матбугатта да, блоглар даирәсендә дә *телеграм-канал* төшенчәсе күп кулланыла башлады. Хаталы язу очраклары бермә-бер артты.

«Телеграм-канал» сүзен татарча русчадан турыдан-туры күчереп язалар, шул рәвешле, рус синтаксисы кагыйдәләрен татар телендә дә кулланырга тырышалар (махсус булмаса да).

Эш шунда ки, рус телендә әгәр аергычның аерылмышка бәйле торган кушымчасы булмаса, алар сызыкча аша языла. Татар телендә исә аергыч белән аерылмышның янәшә торуы җитә (мәсәлән, кызыл_ китап – крас*ная* книга; кавалерист_ кыз – кавалерист-девица).

Без карый торган очракта исә *«Телеграм»дагы* канал турында сүз бара, «Телеграм» – ялгызлык исем. Шуңа күрә, гомуми кагыйдә буенча, аны баш хәрефтән язарга кирәк, ә икенчедән, арасына сызыкча куярга кирәк түгел.

Хәлбуки, WhatsApp кебек үк, «Телеграм» да гади ялгызлык исем булудан туктап, җәмгыять тормышында мөһим урын алып торган социаль күренешкә әверелде. Телеграм каналлар исә – 2017 елларда ук актуальләшкән феномен. Шуңа бу сүзне юл хәрефеннән язу да хата булмас дип уйлыйм: телеграм канал.

Бу кагыйдә башка очракларга да карый: YouTube канал, ютуб канал, онлайн платформа, онлайн белем бирү, онлайн түләү, онлайн сүзлек һ.б.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Коллык

Мин үзем кол булуга баш-аягым белән каршы түгел. Мәсәлән, гомер буе мәхәббәт колы, матурлык, гүзәллек колы булып яшәр идем. Гомумән, тулысынча бәйсезлек берничек тә була алмый ул, тик һәр нәрсәдә чама дигәннәре кирәк. Коллык психологиясе ул еллар буе, әкрен-әкрен формалаша.

Яшь чаклар искә төшеп китте әле. Заманында «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсенең очлы башлы туфлиләре бик модада иде. Натураль күннән, җыйнак иде алар. Бәясе дә нибары 9 тәңкә генә. Безнең заман яшьләре әнә шул туфлиләрнең колына әйләнделәр.

Еллар үтеп, дөньяга ишек-тишекләр ачыла башлагач, без тагын да заманча матуррак туфлиләр барын күрдек. Әле Румыния костюмнары, Финляндиядә эшләнгән мебель һәм тагын бик күп нәрсәләр бездәгедән сыйфатлы булып, совет кешесен үзләренең колларына әйләндерделәр. Совет чорында «Сыйфат бишьеллыклары» да игълан итеп карадылар, җитештерелә торган товарга шәхси келәймә сугу да модага кертелде. Аларның файдасы булмады түгел, әмма икенче яктан безнең ил бәрәңгеләре, кишерләре дә сатылды. Инде менә чит илләр безгә карата төрле санкцияләр, ягъни чикләүләр кертә башлагач, үзебездә җитештерүнең бик мескен хәлдә калганын күреп, импортны алыштыру турында сөйләшә башладык. Кулдан килгәнне үзебездә җитештерү дәүләт сәясәтендә өстенлекле юнәлешкә әйләнде.

Без шулхәтле мескен хәлгә төшкәнбез икән, дөнья базарында аз гына үзгәрешләр башланса, бәяләрне күтәрәбез. Иң кызыгы, мәсәлән, нефтькә бәя күтәрелә икән, бензин бәясе дә өскә сикерә. Нефть арзанайса, бензин да арзанаерга тиеш кебек, әмма мондый хәлне ишеткән дә, күргән дә юк. Юкса «кара алтын»ны читтән сатып алмыйбыз, үзебездә чыга. Нефть эшкәртү заводлары да үзебезнеке. Әмма бәяләр сәясәтенең нинди мантыйкка нигезләнгәнен аңлап бетерә алмыйбыз. Һәрхәлдә, шәхсән үземнең моңа башым җитми.

Күптән түгел бер җитәкче авызыннан хикмәтле сүзләр чыкты. Кайбер азык-төлеккә бәяләр арту “упаковочный материал», ягъни төрү материалы чит илнеке булу белән дә бәйле икән. Нужәли катыргы тартмаларны, целлофан пакетларны анда... үзебез эшли алмыйбыз инде?!

Бүген җитәкчеләребез илнең бай булуы хакында күп сөйли башладылар. Акылыбыз да җитәрлек. Без теләсә нинди санкцияләргә каршы тора алабыз икән. «Икән» дип, дөресе шул инде аның. Галәмгә беренче булып очкан, хәзерге көндә дөньясында тиңе булмаган сугыш кораллары җитештерә алган ил кешесе типкедә яши алмый, яшәргә тиеш тә түгел. Иң югары вазыйфаи затларның чыгышлары күңелне тынычландыра, киләчәккә өмет күзе белән карый башлыйсың. Безнең ил ел авырлыклар аша алга барды һәм авырлыкларны еш кына үзебез тудыра килдек, аннан соң аларны җиңү өчен батырларча көрәштек. Ә бит, бер уйлаганда, матур яшәр өчен артык берни дә уйлап табасы юк.

Мәсәлән, Финляндиягә шалкан бәясенә урман сатып, үзебезгә зур бәядән затлы «финский мебель» кайтартмаска, үзебез үстерә алган җиләк-җимеш, яшелчәне читтән алмаска, ягъни үзебезнең базардан кысрыклап чыгармаска кирәк. Инде килеп, без нигә өчен доллар колы булып яшәргә тиеш ди? Үзен хөрмәт иткән һәр дәүләтнең үз акчасы бар, һәм берсенең халкы да ач-ялангач та түгел, ачка да үлми.

Ил җитәкчелеге безне дошман күргән чит илләргә нефть һәм газны Россия акчасына сатарга карар кылгач, Европа да, Америка да аптырашта калды. Алар үзләре игълан иткән санкцияләргә каршы мондый җавап көтмәгән иде, ахрысы. Шунысы кызык: «Россия акчасы» дигән сүз чыгуга, доллар түбән тәгәрәде, ә безгә Минтимер ага Шәймиев әйтмешли, «Без булдырабыз!» – дип югары күтәрелер вакыт.

ПУЛЬСЫҢ НИЧЕК, ПЛАНЕТАМ?

Сишәмбе көнне Истанбул сөйләшүләре зур бер адым алга атлау белән төгәлләнде. Бәя өчен сүзне нейтраль якка бирик. «Сөйләшүләр башланганнан соң (алдагы раундларны да күздә тотып әйтә. – **Р.Ф.**) иң мәгънәле алгарыш бүген булды», – диде Төркиянең тышкы эшләр министры Чавушугълы. Украина ягы Долмабахчә сарае өстәле янындагы утырышны бик уңай бәяли. Инде алар Президентлар очрашуы өчен кирәкле документларны әзерләп бетерергә җыеналар. Россия делегациясен җитәкләгән Мединский да әлегә телдән генә булган имзасыз килешүләрне «конструктив» дип бәяләде. Кремльнең рәсми позициясе әлегә игълан ителмәде. Һәркем үзенең сәяси зәвыгына бәйле рәвештә ирешелгәннәр хакында «стакан яртылаш буш» дип тә, «яртылаш тулы» дип тә бәя бирә ала. Әмма бер нәрсә хак: планетакүләм масштабта сишәмбенең тарихи очрашуы күтәренкелек тудырды. «Кара алтын» бәясе арзанайды, Америка индекслары югары күтәрелде. Сумның долларга карата курсы да бик нык үсте, әмма монысы – аерым вакыйга.

Керешне озакка сузмыйча, бер нәрсәне искәртик: Украина мәйданында барган конфликт ул – дөньякүләм барган хәлләрнең бер состав өлеше генә. Җир шары масштабында исә зур селкенү бара һәм ул бик зур сәяси һәм икътисади тетрәнү вәгъдә итә. Әлегә тектоник плитәләр Россия – Украина чигендә бәрелешә һәм дулкын котылгысыз рәвештә башка урыннарда кайтаваз бирәчәк. Әйдәгез, бу фикерне Берләшкән Милләтләр Оешмасындагы Россиянең вәкаләтле вәкиле Небензядан раслатабыз: «Россияне икътисади, финанс һәм озак еллар буе көйгә салынган логистик каналлардан изоляцияләргә тырышу инде хәзер үк тарихи масштабтагы кризиска әверелә», – диде ул бу юллар язылыр алдыннан гына. «Тарихи масштабтагы кризис»ны болай дип сыйфатлыйбыз әйдә: соңгы утыз елда без кичергән югалтулар барысы да аның янында бик кечкенә булып күренәчәк. Бу юлларның авторын кара күзлек киюдә гаепләмәгез: ул нәрсә күрсә, шуны җырлый. Аннан соң ул – оптимист натуралы кеше: без бүген кичерә торган һәм иртәгә кичерәчәк хәлләрне (ассызыклыйм: авыр хәлләрне) алтын гасыр тулгагы дип бәяли. Татарның «Бердәү үлми берәү көн күрми» дигән әйтеме бар бит әле. Хәзер яшәп килгән система кабергә кермичә, яңасы тумаячак дип аңлыйбыз моны. Күлдә бата башласаң, аяк-кулларың бәйләнгән булса, өскә калкып чыгуның бер генә юлы бар: төпкә төшеп тәрәлү һәм аяклар белән төптән этелеп, янә өскә калку. Глобаль капитализм диварында барлыкка килгән чатнау иртәме-соңмы стенаның ишелеп төшүенә китерә торган ярыкка әвереләчәк һәм безгә шул җимерекләр астында исән калып, өскә чыгарга тырышырга туры киләчәк. Планетадагы бүгенге хәл менә шундый.

Әйдәгез, аның йөрәк тибешен тыңлап карыйбыз. Халыкара валюта фондының идарәче-директоры Кристалина Георгиева Дохадагы (Катар) форумда берничә көн элек кенә: «Россия – Украина конфликты башка нәрсәләр белән бергә азык-төлек проблемаларына бәйле рәвештә Якын Көнчыгышта тотрыксызлык китереп чыгарырга мөмкин», – диде. Аның фикеренчә, бу яңа «гарәп язы»на этәргеч бирәчәк. Яз дигәч тә, аның хакында матур уйларга ярамый. Беренче «гарәп язы»н искә төшерик. Тунис, Ливия, Мисырдан башланып, очкыны Сүриягә килеп төшкән «яз»ның аяныч нәтиҗәләрен әле дә бетереп булмый. Икенче «яз» була калса, ул тагын да куркынычрак хәлләр вәгъдә итә. Җир шарында вакыйгалар «чылбыр реакциясе» буенча бара, шуңа күрә шаукымы безгә дә кагылачак. Дөньякүләм бик зур трансформациянең башы булачак ул. Кристалина Георгиеваның сүзләрен без расламыйбыз да, кире дә какмыйбыз, әмма зур гарәп фетнәсе – көтелә торган хәл. Бу хакта әлеге юлларның авторы 2011 елның 3 мартында ук матбугатта: «...әле Согуд корольлегенең сәяси давылның нәкъ үзәгендә каласы, фетнәнең иң кызган урыны булып танылачы бар», – дигән юллар бастырган. Георгиева без 11 ел элек әйткәнне бүген кабатлый, бары тик шул гына. Ул ханымның сүзләрен мин аз гына цензура таләпләренә туры китердем. Шул ук язмада Кытай, Америка һәм башка илләрдә дә хәлләрнең катлауланасын фаразлаганмын. Янки гыйсъянчылары Капитолийны кайчан штурмладылар әле?

Кытайга килсәк, эшләр менә болай тора. Россиягә каршы санкцияләргә кушылмаса да, ул барыбер аларны үтәргә мәҗбүр. Кытайга Россия базары да, башка базарлар да бик кирәк, әмма: «Кытай нефть гиганты Sinopec Россиягә инвестицияләрен санкцияләрдән куркып туктата», – дигән юллар укыйбыз без аңлыклар тасмасыннан. Ул гына да түгел, Кытай, Һиндстан, Бразилия, Көньяк Африка Республикасы белән бергәләп Россия нигез салган Яңа үсеш банкы Россиядә эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр. Хәлнең катлаулыгын дәлилләү өчен искәртәбез моны. Кытай инвестицияләре исә Россиягә бик кирәк. Россиянең нефть-газ базары белгече Михаил Крутихин илдә нефть чыгару 6 процентка кимеде, ел ахырына – 25, киләсе ел ахырына 50 процентка кимер, дип фаразлый.

pixabay.com

Янә Кытайга әйләнеп кайтыйк. Аның күчемсез милек базарында токмачлар үткән көздән бирле куера. Зур төзелеш гигантлары, Кытай банклары кредит бирмәгәч, чит ил бизнесыннан бик зур акчаларны әҗәткә җыйдылар һәм хәзер түли алмыйлар. Ни өчен Кытай банклары финансламады? Чөнки төзелеш базарының өметсез икәнен күрделәр. Төзелеш базары алар өчен исә гадәттән тыш зур әһәмияткә ия. Аның эчке тулай продуктының – 25, банк активларының 40 проценты күчемсез милек белән бәйләнгән. Пирамида ишелсә (ул әнә-менә ишеләм дип тора), бөек Кытай кризисы аваз бирәчәк. «Безнең аңа ни катнашыбыз бар?» – дип әйтергә ашыкмагыз. Иң беренче чиратта нефтькә, газга һәм башка чималларга ихтыяҗ нык кимеячәк. Без нәрсә сату хисабына яшибез әле? Менә шул шул. Кытай финанслары гына түгел, аларга әҗәткә биргән башка дәүләтләрнең дә бюджетлары ишелеп төшәчәк. Россиянең америкалылар теше үтмәгән резервлары кайда саклана әле? Кытайда. Кытай аларны бикләмәде, әмма безгә кайтарып та бирә алмый, чөнки санкцияләр капкыны эләктерен алган. Якын Көнчыгыш та чиннар белән бик тыгыз икътисади бәйләнештә тора. Аларда да хәл начараячак.

«Европада хәл начарая, Америкада бәяләр күтәрелә», – дип сөенгән ура-патриотларга җавап бирик. Аларда начараю бездә тагын да начараюга китерәчәк. Аллаһның илчесе көнбатышлылар турында: «Алар бәла-казалардан соң тиз аякка басалар», – дип әйтеп калдырган. Бу – эпохалар алышынганда да үзгәрми торган сыйфаты аларның. Ә менә россиялеләргә ул сыйфат җитеп үк бетми тәсле.

Түбән төшкәннән соң төптән этелеп күтәрелүнең бер үрнәге бар бүген планетада. Ул – Әфганстан. Әфган акчасы акрын гына, әмма даими ныгый. Берничә көн элек кенә Герат провинциясеннән Европага беренче экспорт кәрваны кузгалды. Быелгы бу беренче партиядә 5 миллион долларлык товар бар. Әфганстан үз авыл хуҗалыгын үстерүгә зур игътибар бирә. Быел сугарулы җирләрен 50 процентка җиткерүне күз алдында тоталар. Башка уңышлары да бар. Кайчан гына үзләре безне бугазга-бугаз килгән дошманнарын кичерделәр дә алар белән хезмәттәшлек юлына бастылар таулы ил кешеләре. Россиягә дә кайчан да булса шул юлга әйләнеп кайтырга туры киләчәк. Әмма моңарчы тарихта күрелмәгән зур сынауларны узасы бар әле бөтен планета белән бергәләп.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

МҮКЛӘҮДӘН БИГРӘК ЧУТЛЫЙСЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ятып түгел, атып кал

Казанда яшәүче Рүзәл Галимов шәһәр янындагы Күлле бистәсендә йорт сала башлаган. Узган ел фундаментын салып калдырганнар. Быел аны күтәреп, түбә астына кертеп калдырырга хыяллана ул. «Яңа елга кадәр кирпеч кайтартып калдырган идем. Агач, металл чирәп алырга өлгермәдем. Яңа елдан соң инде алар ике тапкыр диярлек кыйммәтләнде. Төзелеш материаллары янына якын килерлек түгел хәзер. Бәяләре коточкыч. Ләкин эшне ярты юлда калдырып булмый инде. Бурычка кереп булса да, йортны түбә астына кертәсе иде», – ди гаилә башлыгы.

Рүзәл кебек баш ватучылар шактый бүген. Берәүләр: «Үз куышымны булдырырга акчам җитәрме?» – дип борчылса, икенчеләр, төзелеш материалларына бәяләр тотрыкланмасмы, дип өметләнә. Килеп туган вазгыятьтә соңгысына ышаныч ташка үлчим, билгеле. 1 марттан башлап Россиядә төзелеш материаллары 30–40 процентка кыйммәтләнде. Җитештерүчеләр моны безнең илгә карата кертелгән чикләүләр нәтиҗәсе дип аңлатты. Татарстанда күп кенә төзелеш материалларына бәя артуны исә цементка бәя арту белән аңлаталар. Җирле җитештерүчеләр 1 марттан аның хакын тоннасына 500–600 сумга арттырган. Бу узган ел белән чагыштырганда 15–20 процентка күбрәк. Бу, үз чиратында, юл чыгымнарын да арттыра. Чагыштыру өчен: бер ел элек 1 тонна цементны махсус техника белән китереп бирү бәясе 4600 сумнан 5800 сумга җиткән.

Шулай да соңгы көннәрдә бу уңайдан күңелне җылытырлык хәбәр яңгырады. Россия төзелеш министры Ирек Фәйзуллин төзелеш материалларының 9 процентка очсызлануын хәбәр итте. Хәтерләсәгез, Россия Президенты федераль хөкүмәткә төзелеш материаллары җитештерүчеләр белән сөйләшүләр алып барырга, мәсьәләне чишү юлларын эзләргә йөкләмә биргән иде. Шул сөйләшүләрнең нәтиҗәсе буларак, кара металлга бәя арту тукталды. Шул рәвешле ул март аенда 10 процентка арзанайган. Металлга бәйле рәвештә, бүген илдә арматура, агач, пиломатериалларның да хаклары төшә башлаган.

Шуңа күрә белгечләр йорт төзергә, төзекләндерергә җыенган кешеләргә шушы төр товарларны алып калырга киңәш итә. «Икътисадның тотрыксыз чагында төзелеш материалларының очсызлануы – гаҗәп хәл. Аның вакытлы күренеш икәне дә көн кебек ачык. Шуңа күрә мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк», – ди финанс аналитигы Александр Гусев. «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән башка белгечләр дә беравыздан: «Бүген төзелеш материаллары алып калу өчен иң кулай вакыт», – дип белдерде.

Кышын чарасын күр

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов Россиядә төзелеш материалларының даими кыйммәтләнеп торуына китергән тагын бер сәбәпне атый. Ул да булса, ил күләмендә цемент җитештерүче оешмаларның бармак белән санарлык булуы. «Бүген Россиядә төзелеш материаллары эшләгәндә иң киң кулланылган цемент җитештерүче оешмалар саны 5–6дан да артмый. Бу инде базар шартларының камил булмавына китерә. Саклык банкы үз вакытында илебездәге цементның 30 процентын артыгын җитештергән оешманы сатып алган иде. Узган ел исә ул, 161 млрд сумлык килешү төзеп, шушы компанияне шәхси кулларга сатты. Шуңа күрә цементка, цемент кулланыла торган барлык төзелеш материаллары бәяләренең үсүе дә, нигездә, шушы оешмадан торачак», – дип саный.

Дилбегә мондый шәхси оешмалар кулында булганда, төзелеш материалларына хакларны бәйдә тоту бик авыр булачак дип саный белгеч. Бәяләрне киметү өчен, төзелеш материаллары җитештергәндә электр энергиясе, газ куллануга да ташламалы шартлар тудырырга кирәк дигән фикердә ул.

2021 ЕЛДА ТӨЗЕЛЕШ МАТЕРИАЛЛАРЫ *(Илкүләм төзүчеләр берләшмәсе мәгълүматлары нигезендә)*	
Төзелеш материалы	**Күпмегә кыйммәтләнгән**
кирпеч	37,7 процентка
такта	42,4 процентка
түшәмә плитә	25 процентка
битум	42,9 процентка
бетон	15,4 процентка

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Алга таба төзелеш материалларына кытлык булыр дип уйламыйм. Күп кенә төзелеш материалларын үзебездә җитештерәбез бит. Шул ук кирпеч, агач, цемент, ком, бетон эшләнмәләр үзебездә чыгарыла. Шуңа күрә күп кенә җитештерүчеләрнең санкцияләр аркасында дигән булып бәя арттырып куюы бөтенләй башка сыймый. Күбрәк спекуляцияне хәтерләтә бу. Санкцияләр әчке ремонт материаллары хакларына гына тәэсир итә ала. Ник дигәндә, аларның күбесе чит ил валютасына сатып алына. Шул ук вакытта без аларның күбесен Кытайдан кертәбез. Шуңа күрә аларның хаклары да кискен артырга тиеш түгел. Монда һаман да шул Монополиягә каршы хезмәтнең үз эшен тиешенчә башкаруы җитеп бетми, – ди Илгизәр Гайнетдинов.

Икътисадчы, быелгы язда да төзелеш эшләре тукталмас, дип фаразлый. Йорт салырга, йорт төзекләндерергә уйлаган кешегә дә, бәяләрдән куркып, ярты юлда туктап калмаска киңәш итә ул.

– Булган акчаны югалтмауның иң ышанычлы һәм нәтиҗәле юлы бу. Шушы эшкә киләсе елда тотынырга җыенучылар колагына бер киңәш. Кыш көне төзелеш эшләре бераз тукталып тора. Шуңа күрә төзелеш материаллары сатып алу, йорт салуга килешүләрне кыш көне төзергә кирәк. Бөтен чыгымнарны күрсәтеп, килешүне аларның артуына җирлек тудырмаслык итеп төзергә кирәк, – ди белгеч.

Фатир түгел, йорт

Башкаладагы билгеле төзелеш оешмасы җитәкчесе Ильяс Гыймадов: «Йорт салырга хыялланган, яки бу эшкә инде тотынган кешегә бернидән дә курыкмаска, берни дә көтмәскә киңәш итәр идем. Тормыш алга таба бара. Бүген арзанрак бәядән төзелеш материаллары алып калу өчен иң кулай вакыт», – ди.

Оешма башлыгы сүзләренә караганда, соңгы бер айда төзелеш тармагында әллә ни зур үзгәрешләр күзәтелмәгән. Йорт төзү-төзетүгә сорау элеккеге дәрәҗәдә икән. Шуңа күрә төзелеш тармагы алга таба да шундый ук тизлектә эшләячәк дип фаразлый ул. Ильяс Гыймадов төзелеш материаллары тагын да очсызланыр дип өметләнергә дә киңәш итми. «Күп кенә материалларны, әйтик, шул ук кирпечне, 1–2 ай көтәргә туры килә. Димәк, сорау бар. Ә сорау булганда бәяләр тагын да төшмәс», – ди ул.

Өстәвенә тиздән яңа төзелеш сезоны башлана. Оешма җитәкчесе якын арада цемент, ком, вак таш, түбә ябу материаллары кабат кыйммәтләнәчәк, дип фаразлый. Ул китергән саннардан аңлашылганча, йорт төзегәндә кулланылучы җылыткычлар март аенда 10–15 процентка кыйммәтләнгән. Якын арада пенопласт бәяләре дә артыр, дип фаразлыйлар. Ник дигәндә, аны җитештергәндә чит илдән кайтарылган кушылмалар өстәлә. Тәҗрибәле төзүче, цемент, ком, вак таш кебек материаллар хакы да 10 процентка артыр, дип фаразлый. Түбә япканда иң еш кулланылган металл чирәп хаклары янына инде бүген үк якын килерлек түгел. Аның бер квадрат метры 660 сум тора.

– Ни генә дисәләр дә, йорт салу фатир сатып алуга караганда күпкә яхшырак. Шул ук мәйданы буенча гына чагыштырып карасаң да, күпкә отышлырак чыга ул, – ди белгеч.

Кирпеч кыйммәткә төшә

Россиядәге күп кенә эре кирпеч заводларының Татарстандагы дилеры булган оешма җитәкчесе Наталья Кукушкина кирпечне иң нык һәм ышанычлы төзелеш материалы дип саный.

– Мин бу тармакта 14 елдан бирле хезмәт куям. 2008, 2014 елгы кризисларны кичергән кеше. Кирпеч һәрвакыт икътисадның чагылышы булып тора. Андагы вазгыятьне шушы төзелеш материалы аша чамаларга мөмкин. Пандемия чорында кеше билгесезлектә, һәр яңа туган көннән куркып яшәде. Баштарак бу төзелеш тармагына әллә ни йогынты ясамады. Әмма тора-бара кешеләр йорт төзү, төзекләндерү эшләрен күпләп туктата башлады, бу эшне вазгыять рәтләнгәнче дип кичектереп тордылар. Шуңа күрә узган ел җир сатып алу, йорт төзүгә сорау бик нык артты. Шул рәвешле кирпечкә дә сорау котырып үсте. Халык кирпечне кырып-себереп алып бетереп барганлыктан, күпләргә, кирпечкә заказ биргәч, 2–3 ай көтәргә туры килде. Заводта бер-ике айдан чыгачак яңа партия кирпечләр өчен дә алдан акча түләп куючылар булды. Кайбер заводлар хәтта бер елга җитәрлек заказ җыйды, – ди Наталья Кукушкина.

Җитәкче сүзләренә караганда, кирпечкә бүген дә шундый ук коточкыч зур сорау саклана. Башка елларны заводлар кыш буе материал әзерләп, төзелеш чоры башлангач, аларны иркенләп тарата торган булган. Әмма быел заводларда гыйнвар аенда ук кирпеч калмаган диярлек. Шуңа күрә аны узган елгы кебек үк айлар буе көтеп алырга туры килә. Сорау бу кадәр зур булганда, бәяләр дә баштан аша, билгеле. Әйтик, фундамент салганда кулланыла торган кирпеч узган ел 12 сум торган булса, хәзер аны 25 сумнан да очсызгарак алып булмый.

– Кирпеч бәяләре аны җитештергәндә кулланылган чимал, кирәк-яраклар кыйммәтләнү аркасында артты. Мисал өчен, агач бәясе арту белән кирпеч тезгәндә кулланылган поддоннар да кыйммәтләнә. Илдәге вазгыять тә йогынты ясый, билгеле. Төзелеш сезоны башлангач, кирпеч бәясе тагын бераз артырга мөмкин. Әмма бу инде аңа сорауның ни дәрәҗәдә булуына бәйле, – дип ышандыра белгеч. Шул рәвешле хәзер йорт салганда мүкләүдән бигрәк, чутларга туры киләчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТЕШКӘ КЕРЕРМЕ, ТӨШКӘМЕ?

Соңгы ике атнада халык арасында: «Татарстанда ит кытлыгы башланырга мөмкин икән», – дигән хәбәрләр йөри башлады. Әлеге сүзләргә иткә кинәт бәяләр күтәрелү дә өстәлде. Шуңа бәйле рәвештә халыкның шик-шөбһәсе тагын да артты. Бәяләрнең кисәк күтәрелү сәбәбе нидә? Татарстанда ит дефициты булу куркынычы дөреслеккә туры киләме? «ВТ» хәбәрчесе әлеге сорауларга җавап эзләде.

«Булганда алып калыгыз»

Билгеле булганча, һәр атнаның шимбәсендә Казанда һәм тагын берничә зур шәһәрдә язгы ярминкәләр уза. Әлеге чараларның беренче көнендә без Ямашев проспектында урнашкан «Бәхетле» кибете каршындагы ярминкә мәйданына бардык. Көзге ярминкәләр белән чагыштырганда, ит сатучыларның да, ит күләменең дә аз булуына игътибар иттек. Дөрес, ул вакытта сәгать иртәнге 9 тулып киткән иде инде. Бәлки, без чыкканчы сатучылар яхшы гына сатарга өлгергән булгандыр. Чөнки өч ноктада да аларның ите бик аз калган иде.

– Булганда алып калыгыз. Тиздән иткә дә кытлык башланырга мөмкин, – диде Кайбыч районыннан килгән, әмма исемен әйтергә теләмәгән фермер ханым. – Ит бүген бик күп сатылды, шуңа күрә бездә дә аз гына калды. Халык кырылып алды, чөнки ярминкәдә ит артык күп түгел иде. Шәхси хуҗалыклар да, фермерлар да малларын киметә яки бөтенләй бетерә, чөнки азык запасының төбенә кыш көне үк төшә яздык. Терлек асраучыларга болай да җиңел түгел иде, хәзер тагын да авырлашты. Болай да очын очка ялгап баручы фермерлар эшләрен бетерергә мәҗбүр.

Ит белән бәйле вазгыятькә дөрес бәя бирер өчен, ярминкәнең икенче атнасында да чыктык. Бу юлы әлеге төр продукцияне сату нокталары күп, итләр дә мулдан, төрлесен сайлап алу мөмкинлеге зур иде. Без исә берничә сатучы белән сөйләшеп алдык. Аларның берсе Яңа Чишмә районыннан килгән шәхси хуҗалык башлыгы, калганнары Буа, Спас районнары фермерлары иде. Аларның барысы да халыкка сатар өчен итнең азаюын искәртте.

– Мин малларны киметтем, чөнки үзен акламый. Быел кышны көчкә чыктык, азык аз калды. Инде көздән үк малларны эшкәртү ягын карадык, – диде Яңа Чишмә районыннан килгән хуҗалык башлыгы.

Спас районы фермеры да аның сүзләрен куәтләде.

– Әлегә эшкәртеп сата торган малларыбыз бетте дип әйтергә була. Яздан бозаулар сатып алып, хуҗалыкны яңарта башлыйбыз. Дөрес, монда ит сатудан кергән акча бозау сатып алуга да җитми, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кеше башына – 20 кг ит

Татарстан – терлекчелек белән көн итүче республика. Авыл хуҗалыгы тармагында алынган керемнең 70 проценттан артыграгы терлекчелек продукциясен сатудан керә. Узган ел гына республикада 539 мең тонна терлек һәм кош ите эшкәртелгән. Республика Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы китергән мәгълүматлар буенча, Татарстан ит белән үзен тулысынча тәэмин итә. Норма буенча, бер кешегә елына 20 кг терлек ите туры килә. Республика әлеге норманы 25 процентка арттырып үти.

– Ярминкәнең ике көнендә 139,2 тонна терлек (узган елның шушы вакыты белән чагыштырганда 23 процентка күбрәк) һәм 46 тонна дуңгыз ите (узган елның шушы вакыты белән чагыштырганда 100 процентка күбрәк) тәкъдим ителде, – дип аңлатма бирде безгә министрлыкның матбугат үзәге. – Беренче көнне барлык категория продукциягә, шул исәптән иткә дә сорау бик зур булды. Икенче көнне андый чамадан тыш ихтыяҗ күзәтелмәде. Озын чиратлар да, ит җитмәү проблемасы да булмады.

Аксубай районы фермерлар ассоциациясе җитәкчесе Әлфирә Шакирова фикеренчә, соңгы елларда терлек асраучылар кимесә дә, иткә кытлык күзәтелми.

– Без үзебез соңгы бер елда ярминкәләрдә сатмыйбыз, – диде ул. – Ләкин башка фермерлар итләрен тиз арада сатып бетереп кайталар. Уфада торучы туганым ярминкәдән итнең килограммын 650 сумнан алып кайткан. Итне күп дип әйтә алмыйм. Халыкта маллар бөтенләй бетеп килә – асрамыйлар. Сәбәп терлек азыгының кыйммәт булуында гына түгел, халык үзе ялкауланды. Әзергә-бәзер яшәргә өйрәнде. Без үзебез озак еллар маллар үрчетәбез. Аена 3 баш терлек суябыз. Арткы ботларын ярымфабрикатлар ясарга алып калабыз да, алгыларын 380–400 сумнан халыкка сатабыз. Файдасын күрәбез бит. Бу арада гына эшкәртә торган малыбыз юк. Танышым сорагач, эзләп караган идем. Башка фермерлар арасында да эшкәртеп сатучы табылмады. Фермерларда терлек саны кимемәде анысы. Ничек итсәләр итәләр, юлын табалар. Узган ел җитәрлек азык әзерли алмагач, халык малларын көздән үк эшкәртте. Шуңа күрә төп ышанычы – фермерларда.

Итнең килограммы... 730 сум

Ит бәяләренә килгәндә, аларны кем ничек тели, шулайрак куя, ахрысы. Казанның Адоратский базарында алыпсатарлар итнең бер килограммы өчен 730 сум сорый хәтта. Бирегә үк 680 сумга тәкъдим итүчеләр дә бар. «Казан» агросәнәгать паркында итнең бер килограммы уртача алганда 500 сум тора. Авылларда шәхси һәм фермер хуҗалыкларында сатыла торган ит бәясе 380–420 сум тирәсендә тирбәлә. Дәүләт статистикасының 18 мартка булган мәгълүматлары буенча, Татарстанда терлек итенең уртача бәясе – 437,68 сум, ә дуңгыз ите 281,1 сум дип билгеләнә.

Ит белән алыш-бириш итүчеләр, ягъни арадашчылар да ит бәяләренең кинәт өскә сикерүенә басым ясады. Хуҗалыклардан ит сатып алып, аларны комбинатларга тәкъдим итүче Рамил Абдуллин әйтүенчә, әлегә республикада ит дефициты юк.

– Дөрес, азык җитмәү сәбәпле, күп хуҗалыклар малларны симертергә куймауларын әйтә. Дефицит булырга мөмкин, дигән имеш-мимешләр безгә дә килеп ирешә. Ләкин ул ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килә, анысын инде вакыт күрсәтер. Ә менә бәяләр, чыннан да, кискен рәвештә өскә сикерде. Март аенда тере мал сатып алу 20–50 сумга кыйммәтләнде, – диде ул.

Билгеле, ит бәясе күтәрелүгә терлек азыгының кыйммәт булуы да йогынты ясый. Азык кушылмаларының кайбер төрләре буенча уртача сатып алу бәяләре – 50, ашлыкның үзкыйммәте 48 процентка кадәр артты.

Балтач районының фермер-эшмәкәре, мал чалу цехы хуҗасы Рөстәм Исмайлов фикеренчә, ярминкәләрдә тәкъдим ителә торган бәя бик арзан.

– Шәһәр халкы өчен бик арзан бәя ул, тик сатучы гына оттыра, – дип саный эшмәкәр. – Тоткан чыгымнарын, керткән хезмәтен бераз булса да аклар өчен, ярминкәдә үгез ите 480 сумнан сатылырга тиеш, дип саныйм. Алыпсатарлар авыл халкыннан итнең килограммын 370–400 сумнан җыялар.

Бер сыерга – ун кеше

Рөстәм Исмайлов терлекчелек тармагында күптәннән эшли. Аның әйтүенчә, ит бәясе бер ай эчендә кинәт арткан.

– Үгез итенең күпләп сатып алу бәясе 270 сумнан 390 сумга күтәрелде. Мондый хәлнең хәтта иткә дефицит булган елларда да күзәтелгәне юк иде. Күп дигәндә дә 20 сумга арта иде, – ди ул. – Бәя күтәрелүнең төп сәбәбе – Белоруссиядән ит кертү туктатылу. Шул сәбәпле Мәскәү, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрнең аңа ихтыяҗы артты. Ләкин узган атнадан башлап алар тарафыннан сорау кимү күзәтелә. Хәтта шактый итне кире борганнар. Димәк, Белоруссиядән итнең кабат керә башлавы мөмкин. Шулай итеп, сорау ничек кинәт арткан булса, шулай ук кинәт кимеде дә.

Эшмәкәр фикеренчә, авыл хуҗалыгында иткә дефицит сизелә. Моның берничә сәбәбе бар, ди ул.

– Беренчедән, ит читтән кертелми башлады. Безнекеләр исә аңа әзер түгел иде. Терлекләрне кинәт кенә арттыру мөмкин эш түгел. Икенчедән, халык мал асрамый башлады, ялкауланды. Бәяләр артуда аның үзенең дә гаебе бар. Өченчедән, узган ел терлек азыгы әзерләү белән проблемалар килеп чыкты. Хәтта эре хуҗалыкларда да запаслар бетүгә таба бара. Күп маллар көздән үк эшкәртелде. Фермадагы барлык малларын чалучылар булды хәтта, – ди Рөстәм Исмайлов. – Без үзебезнең эштә маллар кимүен бик нык тоябыз. Бүген бер терлеккә ун кеше өмет баглый. Элек ун хайванга бер кеше карап тора иде. Колхозлар да, халык та кем югары бәядән ала, шуңа бирер җибәрә. Көндәшлек яхшы анысы, тик кече эшмәкәрлекнең тамырына балта чаба. Соңгы ике елда бу күренеш аеруча нык сизелә. Татарстанда эшмәкәрлек 2010–2011 елларда чәчәк атты. Мәсәлән, минем чалу цехына көненә районнан гына да 40 сыер чират тора иде. Бүген аларны күрше-тирә районнардан, төбәкләрдән үземә эзләргә туры килә. Шулай булгач, терлек саны буенча вазгыятьне үзегез уйлап карагыз инде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТОВАР АТАМАСЫ	УРТАЧА БӘЯ		БӘЯЛӘРДӘ ҮЗГӘРЕШ (процентларда)
	11.03.22	18.03.22	
Эре терлек ите (сөяксез иттән тыш), кг	426,48	437,68	102,63
Дуңгыз ите (сөяксез иттән тыш), кг	280, 43	281,75	100,47
Сарык ите (сөяксез иттән тыш), кг	515,94	526,92	102,13
Кош ите (тавык ботыннан тыш), кг	155,76	155,66	99,94

«Татарстанстат» мәгълүматлары

8 апрельдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә САДЫЙКОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Кояш батареясын кайдан алырга?

Кояш батареясы урнаштырырга теләгән идек. Аны каян сатып алырга була?

РАМИЛ. Арча районы

«Сетевая компания» оешмасының матбугат үзәге:

– Без андый оешмаларны рекламалый алмыйбыз. Телефоннарын интернеттан табарга мөмкин. Алар бик күп. Кеше әлеге батареяларны бәясенә карап ала. Без күптән түгел Югары Ослан районының Яр буе Морквашы авылында булдык. Фидаевлар гаиләсе Татарстанда кояш энергиясен микрогенерация объекты буларак теркәп, беренчеләрдән булып тоташтырган иде. Бу очракта аларга кояш батареяларын GREENERGO компаниясе куйган. Ике ел элек бәясе 200 мең сумга төшкән. Хәзер бәяләре арты инде. Аның составы чит илдән кайтарыла торган җиһазлардан тора. Шуңа күрә кояш батареялары сатуның тукталып та калуы бар.

Нигә төнлә утны сүндерәләр?

Безнең Әмәкәй авыл җирлегендә төнгә утны сүндерә башладылар. Урамда ут булмагач, бик җайсыз бит. Егылып, бер әби аягын да авырттырган. Баганаларда төнлә дә утлар янсын, акчаны кызганмасыннар иде.

ФӘЙРҮЗӘ. Мөслим районы

Илнара Шакирянова, Мөслим районы Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы:

– Безнең җирлеккә ике авыл керә. Әлмәт авылында – 42, Әмәкәйдә 256 кеше яши. Моңа кадәр ут төнлә дә янып тора иде. Авыл халкы, болай яндырмагыз, утны исраф итмәгез, дигәч, бер ай элек кенә сүндергән идек. Җыелыштан соң шулай сөйләштек. Кичке сәгать 5 тулып киткәч баганаларда утлар кабынып, 11гә кадәр яна. Иртән исә 5 нче ертыда яна башлый һәм яктыргач сүнә. Ике авылда да системаны шулай көйләдек. Көз көне иртә караңгылана башлагач, вакыты үзгәрәчәк.

Юл акчасын дөрес бетергәннәрме?

Мин Теләче районында гомер кичерәм. Улым йортында яшим. Йорт мәйданы – 100 квадрат метр, сигез кеше теркәлгән. Бакча йорт урыны белән бергә 15 сутыйны тәшкил итә. 26 мең сум пенсия алам. Минем исемдә иске машина бар. Шуларны исәпкә алып, юл акчасын бетерделәр. Бу дөрес гамәлме? Шуны ачыкларга ярдәм итүегезне сорыйм.

Миңнехан ЗАКИРОВ, 85 яшь.
Теләче районы

Гүзәл Йосыпова, Теләче районы социаль яклау бүлегенең социаль эшләр буенча белгече:

– 2004 елның 8 декабрендә кабул ителгән «Республика халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында»гы Законда, пенсионерның табышы 20 мең сумнан артып китмәскә тиеш, диелгән. Шуннан арткан очракта юл акчасы бирелми. 2020 елга кадәр табыш күләме 25 мең сум дип билгеләнгән иде. Әмма 2021 елдан законга үзгәрешләр кертелде. Шул сәбәпле Миңнехан Закиров 2021 елның 1 апреленнән юл акчасын алмый башлады.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Пай җиренә күпме түләнергә тиеш?

Пай җирләребез бар, тик аңа акчаны аз бирделәр. Шул ук вакытта күрше авылларда күбрәк түләгән инвесторларны да ишетеп торабыз. Бу очракта аңа түләү күләме буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгеләгән берәр карар юкмы?

Аксубай районы Иске Кыязлы авылы
(исемем редакция өчен генә)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат үзәге:

– Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров тарафыннан имзаланган хатлар районнарга юлланды. Министрлык 2019 елның 23 августында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тарафыннан расланган, авылда яшәүчеләрнең эшлекле активлыгын арттыру мәсьәләләре буенча узган өченче зона семинарының беркетмәсен үтәү өчен, 2022 елда пай җирләренә гектарына 800 сумнан да ким булмаган аренда түләве тәкъдим итә.

Районнарда пай җирләренә акча аз түләүгә бәйле мөрәҗәгатьләр саны арту сәбәпле, аренда килешүләрендә әлеге җирләр өчен түләүне бер гектарга 800 сумнан да ким булмаган күләмгә җиткерү буенча милекчеләр һәм җирне арендага алучылар белән очрашулар уздыру мөһим.

«Галәм» исемен үзгәртеп булмыймы?

Ниһаять, дистә елларга сузылган тартышудан соң, боз кузгалды. Казандагы 18 нче татар гимназиясенә янкорма төзелә. Аны быел 30 августка ачарга җыеналар. 2008 елда уку йортына ябылу куркынычы янаганда, гимназияне Туфан ага Миңнуллин саклап калды. 2020 елда Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенә, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына, шулай ук башкалабызның мәгариф бүлегенә гимназиягә Т.Миңнуллин исемен бирү хакындагы үтенечне юлладым. Барлык оешмалардан да уңай җаваплар алынды.

Соңгы арада 18 нче гимназиягә «Галәм» дигән исем кушу турындагы мәгълүмат килеп ирешә. Бу атама һич тә милли гыйлем учагына туры килми. Аңа олпат шәхес Т.Миңнуллин исемен бирү изге гамәл булыр иде. Әлеге мәсьәләне хәл итүдә булышуыгызны сорыйбыз.

Рания САДЫЙКОВА. Казан

Казан мәгариф идарәсе:

– Бу сорау берничә ел элек тә каралган иде. Ул вакытта автор мөрәҗәгать иткән барлык оешмалар, шул исәптән шәһәр мәгариф идарәсе дә, аның фикерен хуплады, уңай җавап җибәрде. Исем мәсьәләсе уку йортының хезмәт коллективы утырышы карары белән кабул ителә. Гимназия җитәкчелеге Т.Миңнуллин исемен алуга коллективның әзер булмавын белдерде.

Равил Садыйков, Казандагы 18 нче гимназия директоры:

– Бездән генә тормый бит ул. Бу хакта сүзләр күп булды. Әгәр бу исемне алсак, музей эшләргә кирәк булачак. Безнең аңа җитәрлек кабинетлар юк. Мин «Нур» дип тәкъдим иткән идем, тик нигәдер ошатмадылар. Ни өчен дигәндә, Америка, Кытай, Болгария, Чехия вузларында укытучы элекке укучыларыбыз бар. Алар белән горурланабыз. Шуларның фотоларын куеп, нур рәсеме ясап, дөньякүләм татар зыялыларын барларга уйлаган идек. Гимназиянең оешуына – 22 ел. Шушы вакыт эчендә 20 фәннәр кандидаты, профессорлар, 101 медалист тәрбияләдек. «Галәм» исеменә тукталдык.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде.

Укучы сүзе

БАЛАНЫ КАЛДЫРСАМ, ГӨНАҺ БУЛМЫЙМЫ?

Минем бертуган апамның язмышы бу. Ул 2,5 яшьлек баласын әнигә калдырып икенче тапкыр кияүгә китте. Улын эти белән әни тәрбияләде. Аларга «эти», «әни» дип дәште. Армиягә барып кайтты, аннан, өйләнеп, гаилә корды. Ике бала үстерделәр, хәзер зурлар инде. Ул үз әнисендә 1–2 сәгатьлек кунак кына. Шәһәрдә яшәсә дә, авылга еш кайта, ләкин әнисе янына түгел, үскән йортка. Үстергән эти-әнисе күптән гүр иясе инде. Әнисе күрше апа кебек. Исәнме – исән, шуның белән шул. Юньле әни баланы иргә алыштырмый ул.

(Исемсез)

***

Шаккатам шундый хатын-кызга. Ничек инде чит ир дип баланы калдырып китәргә була? Әни булырга язган икән, әни дигән исемне горурланып йөртергә кирәк. Балагыз әниегезгә «әни» дигәндә сезнең йөрәк түзәрме соң?

Рушания ГАЛИЕВА

***

Мин бала белән кияүгә чыктым. Аллага шөкер, кызымны үз балаларыннан артыграк та яратты. Кызым да «эти» дип кенә тора. Мең рәхмәт иремә!

ГҮЗӘЛИЯ

АНА ЙӨРӘГЕНДӘ – БИШ ЯРА

Бигрәк матур Фатыйма апа, күз тимәсен. Бик акыллы, сабыр. Кечкенә чакта мин аларда еш була идем. Беркайчан да караңгы чырай күрсәтмәде. Аңа озын гомер телим. Үз аягында йөреп, сәламәт булып яшәргә язсын.

Гөлнур ХӘМИДУЛЛИНА

СЫЕР САВУЧЫ ГЫНА, ДИМӘСЕННӘР ӘЛЕ

Сыер савучы түгел, хезмәт кенәгәсенә машина белән саву операторы дип яздырышы. Эшнең ояты юк. Бик авыр эш, иртән балаларың белән бергәләп чәй дә эчә алмыйсың. Кич тагын эштә буласың.

Рәмзия ИБРАҺИМОВА

ТЕГҮЧЕ ФАХРИДИН СИДИКОВ: ӘНИНЕ ОЗАТЫРГА КАЙТА АЛМАДЫМ

Мактаныйм әле: биш еллап элек, редакциябездәгеләрдән беренче булып, Фахридны мин таптым! Эш янында гына булган ательега очраклы рәвештә барып кергән идем. Аннары ул башка урынга күчендә, тик, Аллага шөкер, әлләни ерак китмәде. Мин аңа иң катлаулы эшләрне тапшырам. «Моны башка кеше төзәтә алмый», – дим. Чыннан да шулай, кулы алтын. Минем тәкъдим буенча безнең эштәгеләр дә аның ательесына сукмак салды.

Фәния ФӘИЗОВА

ЕРАК КИЛӘЧӘКТӘ «ҖӘМГЫЯТЬ КҮЗӘНӘГЕ» БУЛГАН ГАИЛӘЛӘРНЕҢ ДӘ КИРӘГЕ КАЛМАС...

Бик уйланырлык тема. Минем кияүгә чыгып, дөнья шаукымына ияреп, гаиләсен таркаткан хатын-кызларга исем китә. Иреннән артыгын таләп итә, буй җитмәслек нәрсәләргә үрелә, ахыр чиктә гаилә таркала. Ир гаепле булып кала әле. Үскәндә дөрес тәрбия алмаган, тормышка әзер булмаган кызлар турында әйтәм. Без кияүгә чыккач, иргә буйсындык, өйдәге хәлне тышка чыгармыйча, гаилә учагын җылытырга кирәк дип яшәдек. Әни тәрбиясе шулай булган. Хәзер кайбер хатын-кызлар коточкыч, ирне идән чүпрәге урынына күрәләр. Акыллы, искиткеч кызлар да күп.

ДАНИЯ апагыз

4 апрель | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 17.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Рәхәт яшибез». Телесериал 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «КАЙДА СИН?» 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 Док. фильм 12+
23.50 «Каравай». Живопись – часть национальной культуры 6+
00.15 «Ком сәгате» 12+
01.05 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. Евгения Брик. «НИКТО НЕ УЗНАЕТ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00, 20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «СОФИЯ» 16+
02.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 16+
03.30 СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.50, 12.30, 15.00, 18.00 Новости
06.05, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.55, 12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
09.15 «ПЕЛЕ: РОЖДЕНИЕ ЛЕГЕНДЫ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
14.00, 15.05 «АГЕНТ» 16+
17.00 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
18.05 «Громко». Прямой эфир
19.00 Хоккей. КХЛ. Финал конференции «Запад». СКА (Санкт-Петербург) – ЦСКА. Прямая трансляция
21.45 Футбол. Чемпионат Италии. «Милан» – «Болонья». Прямая трансляция
00.20 Тотальный футбол 12+
00.50 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар) 0+
02.40 «Есть тема!» 12+
03.00 Новости 0+
03.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Фрайбург» – «Бавария» 0+
05.15 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.30 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Владимир Епифанцев. «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
23.45 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.45 «Таинственная Россия» 16+
03.25 Сериал «ХМУРОВ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Чёрные слёзы» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
19.00 «САШИНО ДЕЛО» 16+
23.05 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.00 «АНЖЕЛИКА – МАРКИЗА АНГЕЛОВ» 16+
04.00 «ПРОВОДНИЦА» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «КУЛИНАР» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 01.30 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «КУЛИНАР-2» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Война миров». Док. сериал. «КГБ против ЦРУ. Операция «Трианон» 16+
21.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. Премьера! 12+
22.15 Новости дня 16+
22.30 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.55 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №97». Премьера! 16+
23.40 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ-3» 16+
03.05 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.35 «КУЛИНАР-2» 16+

5 апрель | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.00 Док. фильм 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники» 12+
00.40 «Каравай» 12+
01.05 «Не от мира сего...» 12+
01.35 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «ӘНИЕМНЕҢ ЖЫЛЫ КОЧАГЫ» 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00, 20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «СОФИЯ» 16+
02.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 16+
03.30 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.00 Новости
06.05, 21.10, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 Смешанные единоборства. Strikeforce. Даниэль Кормье против Джоша Барнетта. Трансляция из США 16+
10.00 Профессиональный бокс. Трансляция из Москвы 16+
11.00 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
12.55 «Главная дорога» 16+
14.00, 15.05 «АГЕНТ» 16+
16.55 Хоккей. КХЛ. Финал конференции «Восток». Прямая трансляция
19.20 Смешанные единоборства. UFC. Петр Ян против Жозе Альдо. Трансляция из ОАЭ 16+
20.15 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
21.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Манчестер Сити» (Англия) – «Атлетико» (Испания). Прямая трансляция
00.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Бенфика» (Португалия) – «Ливерпуль» (Англия) 0+
02.40 «Есть тема!» 12+
03.00 Новости 0+
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. «Депортиво Кали» (Колумбия) – «Бока Хуниорс» (Аргентина). Прямая трансляция.

НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.30 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
23.45 «ПЁС» (S) 16+
02.45 «Таинственная Россия» 16+
03.25 Сериал «ХМУРОВ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Найти и потерять» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ВРЕМЯ УХОДИТЬ, ВРЕМЯ ВОЗВРАЩАТЬСЯ» 16+
19.00 «РАЗВЕ МОЖНО МЕЧТАТЬ О БОЛЬШЕМ» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.00 «ВЕЛИКОЛЕПНАЯ АНЖЕЛИКА» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «КУЛИНАР-2» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 01.30 «СТАРИКИ-РАЗБОЙНИКИ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «КУЛИНАР-2» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Война миров». Док. сериал. «Нас боялись не венгры» 16+
21.25 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
22.15 Новости дня 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды армии». Николай Еловик 12+
23.40 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ-3» 16+
03.00 «Раздвигая льды» 12+
03.35 «КУЛИНАР-2» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Агросәнәгать комплексына югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Сарман аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Агелтдинов** Зөбәер Зәйнетдин улы; татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе, актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «Санкт-Петербургның татар милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары **Алюшев** Шамил Абдул улы; республикада музей эшен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авылы «Халыклар дуслыгы» туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Галиев** Гарифҗан Гали улы; күпьеллык намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Клюкин** Виталий Николаевич; Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Рейнлиб** Михаил Израильевич; массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» филиалы радиотапшырулар хезмәте башлыгы **Сәгыйтов** Тәүфикъ Камәртдин улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Транспорт тәэминаты өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге машина йөртүчесе **Макаров** Василий Михайлович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Милләтләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасының рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе **Александровская** Ирина Алексеевна, «Татарстанның немецлар милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Диц** Виктор Георгиевич, «Татарстан Республикасының кыргызлар милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Муканбетов** Бейшенбек Аскербай улы, «Татарстан Республикасында чувашларның милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Тимофеев** Володар Аркадьевич, «Татарстан Республикасының әрмәннәр милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Хачатурян** Михаил Викторович; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Гыйниятуллин** Әсхәт Гыйниятулла улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераннары: **Исанова** Вәлидә Адим кызы, **Лотфуллин** Рөстәм Хәбибрахман улы, **Максимов** Юрий Александрович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Матбугат хезмәте өлкән белгече **Мөхәммәтҗанов** Эдуард Рәхимҗан улына **«Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:170115:300, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, СДТ «Табигать», участок 298 проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Яхин Рустем Рашитович (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 89030618183).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 4 мая 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63 с 04.04.2022 г. по 04.05.2022 г.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ земельных участков с кадастровыми номерами:

16:50:170115:302, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, СДТ «Табигать», участок 300;

16:50:170115:752, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, СТ «Табигать», участок 296.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО 0182, дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085, в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:213701:292, расположенного по адресу Республика Татарстан, г. Казань, с/т «Сад №10 КМПО», уч. 40а, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Быкова Е.С. (тел.: 8-9061157658). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 5 мая 2022 г. в 10.30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются ежедневно с 9 до 17 часов с 5 апреля 2022 до 5 мая 2022 по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежный земельный участок с правообладателем, которого требуется согласовать местоположение границ, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, с/т «Сад №10 КМПО», уч. 27.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

УРАЗАДА НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?

Изге рамазан аена аяк бастык. Иртәгә – уразаның беренче көне. Бу чорны организмга авырлык китермичә, җиңел генә уздыру өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Сәхәр һәм ифтарда нәрсә ашарга?

Ураза тотканда дөрес туклану турында табиб-терапевт, нутрициолог Элина БОРҺАНОВА сөйләде.

:: Элина Газинуровна, нинди чирләр вакытында ураза тотмау хәерле икәнен тагын бер кат искә төшерик әле.

– Үт куыгы, эчәклек, ашказаны, бавыры авыру кешеләргә, хроник авырулары кузгалганнарга ураза тотмау хәерләрәк. Балаларга, йөкле яки бала имезүче хатын-кызга ураза тотарга ярамый. Гомумән, ураза тотар алдыннан табиб белән киңәшләшергә кирәк.

:: Күп итеп су эчкән кеше уразаны җиңелрәк тота, диләр.

– Бу дөрестән дә шулай. Сәхәргә торгач, ашарга ярты сәгать кала 1–2 стакан су эчеп куярга кирәк. Шуның артыннан ук ярты стакан минераль су да эчегез. Ул организмны уятып җибәрә, аны ашарга әзерли, натрий, калий, кальций белән баета. Әмма бу урында шунысын да искәртеп китәргә кирәк: үт куыгында таш булган кешегә минераль су эчәргә ярамый. Чиста су исә беркемгә дә зыян итми. Гомумән, ураза тоткан кешегә сәхәр, ифтарда мөмкин кадәр күбрәк чиста су эчәргә кирәк. Ул организмга бу чорны җиңелрәк үткәрергә ярдәм итәчәк.

:: Сәхәр һәм ифтарда нәрсәләр ашау хәерле?

– Һәр икесендә дә идеаль тәлинкә кагыйдәсен истә тотарга киңәш итәр идем. Ул нидән гыйбарәт? Монда сезнең тәлинкәнең дүрттән бер өлешен – аксымлы ризыклар (йомырка, эремчек, балык, ит), тагын дүрттән берен ботка, токмач, ипи кебек авыр углеводлы ризыклар тәшкил итәргә тиеш. Ипи дигәндә кара ипи күздә тотыла. Агын ашаганда кандагы шикәр күләме күтәрелә. Ач торганда исә ул кабат төшә. Шул рәвешле организмга авырга туры киләчәк. Аксым һәм углеводлардан тыш, тәлинкәнең тагын дүрттән бер өлешен – яшелчә, калганын җиләк-җимеш алып торырга тиеш. Соңрак шушы ризыкларга бер аш кашыгы май да, чикләвек тә өстибез. Чикләвек яхшы үзләштерелсен өчен ашар алдыннан аны суда тотарга киңәш ителә. Шушы кагыйдәләрне истә тотканда организм көне буена җитәрлек энергия туплаячак. Ифтарда да шуларны ук ашыйбыз. Ник дигәндә, безгә тәүлек дәвамында шушы ризыклар кирәк. Дөрес, ифтарда идеаль тәлинкә күләме зуррак та булырга мөмкин. Моның бер зыяны да юк. Ашаганда ризыкны яхшылап чәйнәгез.

:: Уразада җиләк-җимешләрне кайчан ашау яхшырак?

– Аларны сәхәрдә дә, ифтарда да ашасаң ярый. Иң мөһиме – күләме сакланысын. Әйткәнемчә, җиләк-җимеш тәлинкәнең дүрттән бер өлешен алып торырга тиеш. Кич җиләк-җимеш ашарга ярамый – тазарта, дигән фикерне дә еш ишетергә туры килә. Аны күпләп – килограммлап ашау зыянлы, билгеле. Ләкин кич бер алма яки мандарин ашап куюның бер зыяны да юк.

:: Ашны кайчан ашасаң да ярыймы?

– Ашны сәхәрдә ашасаң да, ифтарда ашасың да ярый. Иң мөһиме – ул туклыклы, итле булсын. Ашны ипи белән ашарга кирәк. Сәхәрдә генә түгел, гадәти тормышта да иртүк аш ашаучылар байтак. Кеше иртүк шулпа ашый алса, бу аның үт куыгы яхшы эшли дигән сүз.

nurlat-tat.ru

:: Ураза тотканда кайсы төр ризыкларны ашамау хәерле?

– Көне буе ач торганнан соң кисәк кенә ачы, тозлы, ысланган, кыздырылган, камыр ризыгы кабып кую организмга бик зур зыян салырга мөмкин. Ул шок кичерәчәк. Шуңа күрә бу ризыкларны ашаганчы организмны әзерләгез. Иң элек яшелчә, аш ашап алыгыз. Уразаның беренче ике атнасында «Мезим» кебек фермент дару эчеп алу да комачауламас.

:: Дару дигәннән, ураза тотканда дару, витаминнарны кайчан эчәргә?

– Табиб иртәнге аштан соң дип язып биргән даруларны – сәхәрдән соң, кичке аштан соң эчәселәрен ифтарда эчәргә кирәк. Җитди дарулар турында сүз барганда, табиб белән киңәшләшергә кирәк. Көненә өч тапкыр дару эчәргә кирәк икән, уразаны калдырып тору хәерлерәк. Витаминнарны сәхәр белән ифтарда эчәргә мөмкин. Мин, гомумән, витаминнарны ризык белән алу яклы. Алда телгә алынган идеаль тәлинкә принцибы белән тукланган вакытта без көн дәвамында организм өчен кирәкле барлык файдалы матдәләрне алабыз. Мәсәлән, ярмалар, ипи белән организмга магний, В төркемендәге витаминнар керә. Яшелчә, үләннәр фолий кислотасы, С витаминына бай. Сары, кызыл яшелчә, җиләк-җимешләрдә А витамины бар. Майлар белән Е витаминын алабыз. Чикләвекләр – файдалы майлар, цинк, селен, бакыр чыганагы. Эремчек белән көнҗетә – кальций, хөрмәдә калий күп. Д витаминын гына ризык аша алып булмый. Шуңа күрә аны төймә рәвешендә эчәргә туры килә. Профилактика өчен аны көн саен 800–1000 берәмлек кулланырга кирәк. Әлеге витаминны иртәнге якта эчәргә кирәк. Ник дигәндә, ул йокыны качыра.

Кишер томаудан коткара

Борынга томау төшүдән котылу өчен 1 аш кашыгы кишер согы белән 1 аш кашыгы үсемлек маен бутап, шуна 1–2 тамчы сарымсак согы өстәргә кирәк. Аны берничә тамчы күләмендә көненә 3–4 мәртәбә борынга салырга киңәш ителә. 1:1 күләмдә болгатылган су белән бал катнашмасы салуның да файдасы тими калмас. Аны борынга 2–3 тамчы күләмендә көнгә 3 тапкыр салырга мөмкин.

ЖЫЕРЧЫКЛАРНЫ КИМЕТҮ ӨЧЕН ГИМНАСТИКА

Витаминда түгел хикмәт

Язын әллә нинди ят ризыклар ашыйсы килә башлый, эч эзләнә. Кайчак хәтта бөтенләй яратмаган ризыкларны да ашап куясың. Баксаң, организмдагы мондый «сәерлек»кә язгы витаминнар кытлыгы гына гаепле түгел икән. Теге яки бу ризыкны ашыйсы килү тәнгә кешедә җитди чир барлыгы турында да кисәтергә мөмкин.

Суган, сарымсак, тәмләткечләр. Мондый ризыкларга карата кисәк кенә мәхәббәт хисләре уяну сулыш юлындагы хилафлыклар турында да сөйләргә мөмкин.

Калкансыман биз эшчәнлеге бозылганда **зәйтүн җимеше**нә ихтыяҗ барлыкка килә ала.

Углеводлар алмашы бозылган, гипогликемия яки шикәр чиреннән интеккән кеше, гадәттә, **туңдырма**га мөкиббән китә.

Бананга битараф булмаучыларга йөрәген тикшертеп алса зыян итмәс.

Көнбагыш чиртергә яратучылар исә организмны вакытыннан алда картаюдан саклаучы антиоксидант-витаминнарга кытлык кичерә.

Кирәге чыгар

Иммунитетны ныгытабыз

Язын иммунитетыбыз аеруча ярдәмгә мохтаҗ. Аны ныгытуда имбиргә тиңнәр юк. Аның тамырында микроэлементлар, аминокислоталар, эфир майлары бар. Моннан тыш ул B_3, B_6, B_9, С һәм А витаминнарына да бай. Иммунитетны ныгытучы катнашма әзерләү өчен 300–350 грамм имбир тамыры, 150–200 грамм бал һәм 1–2 лимон кирәк булачак. Иң элек имбир тамырын чистартып, зур булмаган кисәкләргә бүләбез. Лимонны өлешләргә кисеп, орлыкларын алабыз һәм икесен дә иттарткычтан чыгарабыз. Бал кушып, яхшылап болгатабыз. Профилактика өчен аны көнгә бер бал кашыгы ашарга яки чәйгә бутарга кирәк. Катнашма бик әче. Ашказаны-эчәк авырулары көчәйгән чорда имбирдән баш тартып тору хәерле. Катнашманы банкага салып, суыткычта сакларга кирәк.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТӘРӘЗӘ ТӨБЕМ САЕН ҮСЕНТЕ...

Хәзер күпләрнең тәрәзә төпләрен помидор, борыч үсентеләре ямьләп утыра. Ләкин алар бик нәзберек. Берәр нәрсә килешмәсә, аларның йә «төсләре китә», йә сузылып, хәлсезләнеп утыра башлый. Үсентеләр шаулап үссен өчен аларны ничек дөрес тәрбияләргә? Әлеге сорауга бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВА белән җавап эзләдек.

pixabay.com

:: Үсентеләрнең кубесен кучереп утыртык инде. Әмма яфраклары төсен үзгәртә, коела башлады, дип зарланучылар бар. Бу очракта нишләргә?

– Яфракның төсен үзгәртүе үсентегә нәрсәдер җитмәгәнне аңлата. Тимер җитмәгәндә, яфрак агарып, төссезләнеп китә. Үсенте сабагы һәм яфракларның аскы өлеше шәмәхә төскә керсә, фосфор җитми, яфраклар саргайса һәм коела башласа, азот җитми дигән сүз. Мондый очракларда үсентеләрне рәткә китерү өчен төрле ашламалар бар. Шәхсән мин үзем үсентеләргә табигый эремә сибүне кулай күрәм. Моның өчен чүпрә эремәсен кулланам. 10 литр суга 10 грамм чүпрә, 4 аш кашыгы шикәр комы исәбеннән эремә ясыйм. Ул әчергә тиеш. 1 өлеш эремәгә 10 өлеш су өстәп, үсентеләр төбенә сибәргә киңәш итәм. Әлеге табигый ашлама үсентеләрне көчәйтеп, яфракларын яшелләндереп җибәрә. Гөмбәчекләрдән саклау өчен су белән бераз гына йод кушып сибү файдалы.

:: Помидор үсентесе сузылып үссә, нишләтергә?

– Гадәттә орлыкны бик иртә – февраль башларында ук чәчкән очракта шулай була. Күчереп утыртканда, томат үсентесе 60–65 көнлек булырга тиеш. Үсентеләрне теплицага яки ачык туфракка кайчан утыртырга планлаштырасыз, шул сроктан артка таба санап, тишелү өчен биш көн өстәргә кирәк. Безнең якларда помидор үсентеләре ачык туфракка гадәттә 10 июнь тирәсендә күчереп утыртыла. Шуңа күрә ачык грунтта үсәчәк помидорларны апрель башында гына чәчәргә кирәк. Сабакның сузылып үсүе яктылык җитмәүгә, шулай ук бүлмә һавасының бик җылы булуына бәйле. Үсентеләр кимендә 12 сәгать дәвамында яктыда торырга, тәрәзә төбендәге температура – көндез 20–21, төнлә 18–19 градустан артмаска тиеш. Кояшлы көннәрдә форточканы ачып җилләтергә, температураның 23–25 градустан күтәрелмәвен күзәтеп торырга. Ә инде күчереп утыртырга ике атна кала, үсентеләрне теплицага яки балконга алып чыгып чыныктырырга кирәк.

:: Үсентеләргә су сибүнең дә үз җае бар бит.

– Аларга кар, яңгыр суы сибү файдалы. Әмма су җылы – 20–25 градус чамасы булырга тиеш. Краннан агызып алган суны бераз тотканнан соң гына сибәргә кирәк. Туфракның өсте катып китсә, һава керми. Шуңа күрә үсенте төпләрен саклык белән генә йомшартып торырга онытмагыз.

:: Май башларында теплицага күчереп утырту өчен кыяр чәчәр вакыт җитеп килә. Бу эшне кайчан һәм ничек башкарсаң дөресрәк?

– Апрельнең беренче декадасында чәчсәң, май башларында теплицага күчереп утыртырлык була инде алар. Зуррак савытларга (300 мл чамасы сыешлыктагы) чәчү әйбәт. Тулыр-тулмас туфрак тутырып, су сибәбез. Һәр савытка 1–2 орлык салып, 1,5–2 см тирәнлектә чәчәбез һәм дымсу туфрак белән каплыйбыз. Чәчкәннән соң су сипмибез, юкса орлыклар тирәнгә үк төшеп китәчәк. Чүлмәкләрне пленка белән каплап, җылы урынга куябыз.

Исеңдә тот!

Чәчәр алдыннан кыяр орлыгының буш түгелләрен болай белергә мөмкин. Бер стакан суга бер чәй кашыгы тоз салып, тулысынча эреп беткәнче болгатабыз. Эремәгә орлыкны 10 минутка салып торабыз. Әйбәт орлыклар аска төшәчәк, ә бушлары өскә калкып чыгачак. Тозлы судан соң әйбәтләрен юып киптерәбез.

Йомырка пешерү серләре

✓ Суыткычтан алуга кайнар суга салу кабыгы ярылуга китерә. Шуңа күрә пешерергә кимендә ярты сәгать кала аны бүлмә температурасында тотарга кирәк. Шундый ук температурадагы суга салып, кайнап чыкканнан соң сүрән утта 7 минут пешерергә.

✓ Кайвакыт пешкән йомырканың кабыгы начар куба. Эшне җиңеләйтүнең гади генә сере бар. Йомырка пешкәч, кәстрүлдәге суын агызабыз. Кабыгы чатнасын өчен кашык белән җиңелчә генә суккалыйбыз да өстенә салкын су салабыз. Су кабык астына кереп тулганлыктан, йомырка бик җиңел чистартылачак.

Киңәш

Ачылып аптыратса

Киемнең замогы тотмый башладымы? Тешләренә чәч лагын сиптерегез дә шундук замоклап куегыз. Лакның тулысынча кибүен көтегез. Шуннан соң инде киемне курыкмыйча кияргә мөмкин. Болай эшләгәндә, замок башка беркайчан да аерылмаячак.

Хуҗабикәгә

ТОЗ ФАЙДАЛЫ ДА БУЛА

Соңгы араларда иң кадерле продуктларның берсенә әйләнгән тозның файдасына караганда зыяны күбрәк, диләр. Ләкин, белгечләр әйтүенчә, тозның сәламәтлек өчен файдалы төрләре дә бар.

▶ **Аш тозы (поваренная соль).** Иң күп кулланыла торган төре. Производствода катнашмалардан бик җентекләп чистартыла. Шул ук вакытта тимер, бакыр, калий кебек файдалы матдәләре юкка чыга. Бөртекләләнеп торсын өчен сусызландыралар, шуннан, агартып, калий йодиды өстиләр.

▶ **«Экстра» тозы.** Иң зарарлы тозларның берсе булып санала. Аны җитештерүдә сода белән чистарту ысулы кулланыла. Шулай ук төрле химик катнашмалар өстәлә. Нәтиҗәдә файдалы компонентлары калмый.

▶ **Һималай тозы яки алсу тоз.** Соңгы вакытларда нәкъ менә шуңа өстенлек бирүчеләр ишәя. Составында файдалы микроэлементлар (калий, кальций, магний, фтор) күп булуга гына түгел, матурлыгына да бәйле бу. Мондый тоз аш-су өчен генә түгел, косметологиядә дә киң кулланыла. Алсу төсен аңа составындагы тимер оксиды бирә. Һималай тозы Һималай таулары тирәсендә – Пакьстанда чыгарыла.

▶ **Диңгез тозы.** Башлыча табигый юл белән чыгарыла. Шуңа күрә магний, калий, сульфат кебек файдалы матдәләргә бай.

▶ **Йодлы тоз.** Аш тозыннан аерылмый диярлек. Организмга йод җитмәгәндә куллану киңәш ителә.

▶ **Кара тоз.** Мондый тоз күкертле водородка ия булган җирләрдә чыгарыла. Сатуга асылда чистартылмаган килеш килеп керә. Галимнәр фикеренчә, сәламәтлек өчен иң әйбәт тоз.

Кайсын сайларга?

Аш һәм «Экстра» тозында, бик җентекләп эшкәртелгәнлектән, файдалы матдәләре калмый диярлек. Алсу, кара тозларга, шулай ук диңгез тозына өстенлек хәерлерәк. Ләкин файдалы саналса да, аны тәүлегенә 5 граммнан артмырга ярамый.

Тәмле булсын!

КЕТЕРДИ ТОРГАН ӨЧПОЧМАК КАМЫРЫ

Айгөл Муллагалиева рецепты

Кирәк булачак: *ярты стакан җылымса су, 2/3 стакан җылымса сөт, 1 йомырка, 100 грамм эретелгән сыер мае, 2–3 аш кашыгы үсемлек мае, кирәгенчә он һәм тоз.*

Барысын бергә салып, йомшак кына камыр басабыз. 15–20 минут ял иттергәннән соң өчпочмаклар ясыйбыз. Мондый камырдан пешерелгән өчпочмакларның тышы кетердәп тора һәм искиткеч тәмле була.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

СҮЗЕҢДӘ ФАЙДА БУЛМАСА, ДӘШМӘҮ ХӘЕРЛЕ

Сәхабәләрнең берсе: «Төрмәгә ябарга иң лаек әгъза ул – тел», – дигән. Чынлап та, тел сөяксез һәм ул яхшы сүзләрне дә, гөнаһка этәрә торганнарын да әйтә. Телдән ычкынган сүз өчен үкенгән чаклар да булгалый. Сүзне үлчәп сөйләү турында динебездә ни диелә? Мөселман кешесенә сүгенергә ярыймы?

Бу һәм башка сорауларга Наил хәзрәт ЙОСЫПОВ җавап бирде.

:: «Кем дә кем миңа авызы эчендәге (телен) һәм ике аягы арасындагы (җенес) әгъзасын сакларга вәгъдә итсә, мин аңа җәннәт вәгъдә итәм» дигән хәдис ишеткән бар. Бу инде безгә – мөселманнарга сүзне үлчәп сөйләргә дигән күрсәтмәдер? Мөселманнарның сөйләшү әдәбе турында аңлатып узсак иде.

– Әйе, без – адәм балалары телебезне Аллаһның ачуын чыгара торган гамәлләрдән сакларга тиеш. Мөселманнарның сөйләшү әдәбенә килгәндә, һәр мөэмингә әйтәсе сүзен уйлап һәм үлчәп сөйләү хәерле. Әгәр дә аның әйтәчәк сүзендә файда булмаса, бу очракта иң яхшысы – дәшми тору. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в): «Кем дә кем Аллаһка һәм кыямәт көненә ышанса, хәерле сүз әйтсен яки эндәшмәсен», – дип әйтә. Хәерле сүзгә динебездә яхшылыкка өндәү, начарлыктан тыю, Аллаһны искә алу, кешеләрне шатландыра торган сүзләр керә. Әгәр дә кеше әйтәчәк сүзенең файда китерүенә шикләнсә, аны әйтмәү хәерле.

:: Тел белән кыла торган гөнаһлар нинди?

– Тел белән кыла торган гөнаһлар: ялган, гайбәт сөйләү, сүз тарату, сүгенү, кешене мыскыл итү, түбәнсетү.

:: Сүз кешене үстерә дә, үсендерә дә, үтерә дә. Мөселман кешенең сөйләме нинди булырга тиеш?

– Дөрес, сүз белән кешене дәваларга да һәм гариплэндерергә дә була. Әбү Муса әл-Әшгари әйтә: «Мин әйттем: Әй, Аллаһның илчесе! Мөселманнарның кайсы иң хәерлесе?» Ул әйтте: «Башка мөселманнар аның теленнән һәм кулыннан имин булган кеше». Кеше нинди генә сүз сөйләмәсен, аның һәр сүзе ике фәрештә тарафыннан язылып барыла. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Ике кабул итүче (язып баручы) фәрештә (кешедән чыгучы бөтен нәрсәне теркәп бара). Алар уң якта һәм сул якта утыра. Ул нинди генә сүз әйтмәсен, аны инде күзәтүче фәрештә (язарга) әзер тора». Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в): «Адәм баласы иртә белән торгач, бөтен әгъзалар да телне орышып, аңа шулай диләр: «Безнең өчен Аллаһның газабыннан саклан! Дөреслектә, без сиңа бәйле. Әгәр дә син туры юлдан барсаң, без дә туры юлдан барабыз, әгәр дә син туры юлдан чыксаң, без дә туры юлдан чыгабыз», – ди.

:: Кыямәт көнендә кеше хәтта уйламыйча әйткән сүзләре өчен дә газапка тартыла, ди. Моны раслаучы хәдисләр бармы?

– Ошбу хәдис Имам Бохари китабы җыентыгында китерелә, Мөхәммәд (с.г.в): «Дөреслектә, кеше үзе дә игътибар итмичә Аллаһ риза була торган бер сүз әйтә һәм Аллаһ шуның белән аны дәрәҗәләргә күтәрә. Шулай ук кеше үзе дә игътибар итмичә Аллаһның ачуын чыгара торган бер сүз әйтә һәм Ул аны шуның аркасында җәһәннәмгә ата», – ди.

Әл-Хәсән әл-Басри исә: «Элекке вакытта шулай дип әйтәләр иде: «Мөэминнең теле йөрәге артыннан йөри. Әгәр дә ул берәр нәрсә әйтергә теләсә, башта аның турында йөрәге белән уйлый, ә аннан соң әйтә. Монафикъның теле йөрәге алдыннан йөри. Әгәр дә ул берәр нәрсә әйтергә теләсә, аны теле белән әйтә, ә йөрәге белән аның турында уйламый», – дип китерә.

:: Сүгенү сүзләре кыстырып сөйләшү турында диндә ни диелә?

– Ислам динендә сүгенү катгый тыела, чөнки һәрбер сүгенү ул кемнедер кимсетү яки кемнеңдер хакын алу булып тора. Ә инде кеше хакына керү, аның дәрәҗәсен төшерү вә мыскыллау безнең диндә тыелган. Рәсүлебез әйткән: «Кешеләрне сүгү вә дәрәҗәләрен төшерү – ямьлык һәм кеферлек гамәле». Сүгенү сүзләре күбрәк кешенең җенси әгъзасын һәм ир белән хатын-кыз арасында була торган җенси мөнәсәбәтне искә алу, шуларга кагылышлы гамәлләр хакында. Уйлап кына карагыз: акылы булган кеше сөйләмендә гаурәт урынны һәм кайбер җенси мөнәсәбәтләрне белдергән сүзләрне кулланырмы? Юк! Чөнки андый сүзләр һәрбер юньле кешенең дәрәҗәсен төшерә һәм бер үк вакытта аны бик каты мыскыллый. Шул сәбәпле мөселман кешенең янында торган башка берәүне сүгәргә һәм аның каршында сүгенеп холыксызланып торырга бернинди дә хакы юк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Өч хәдис

- *«Бөтен җанлы мәхлукка карата яхшы мөгамәләгез өчен әҗер-саван булачак».*
- *«Үзегездән югары булганнарга түгел, ә үзегездән түбән булганнарга карагыз. Бу сезгә Аллаһының нигъмәтләрен аз дип күрмәскә ярдәм итәр».*
- *«Аллаһы Тәгалә каршысында Җир йөзендәге потка табынучы кешеләрдән иң җирәнгечләре – нәфес теләкләренә табынучылар».*

Белеп тор!

Хуш киләсең, рамазан!

Һәр мөселман өчен кадерле һәм мөһим айга аяк бастык. Рамазан җиткәч, җәннәт капкалары ачыла, диләр. Изге айның фазыйләтен югары күтәреп, пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән:

«Бу айда 4 төрле әйберне күбрәк эшләгез: икесе Аллаһы Тәгалә сездән разый була торган, ә икесе – үзегезгә бик кирәкле гамәлләр. Беренче ике гамәл – шәһадәт китерү һәм тәүбәләр кылу. Икенче ике гамәл – Аллаһыдан җәннәт сорап, Аңа ут газабыннан сыенудыр».

Барыбызга да бу айны бәрәкәтле итеп уздырырга, күбрәк игелек кылырга язсын!

pixabay.com

УРАЗАНЫ НӘРСӘ БОЗА?

Уразаны түбәндәге дүрт төрле эш боза: борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йотү; бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йотү; җенси якынлык кылу; авыз тутырып косу; тәмәке тарту; кан салдыру; бәлә торып ашау.

УРАЗА ТОТКАНДА НИЛӘР КИҢӘШ ИТЕЛМИ?

Ризыкны татып карау, сагыз чәйнәү, теш пастасы куллану, какырык йоту, шәһвәт уянырлык итеп ир белән хатынның кочаклашуы, үбешүе.

КЕМНӘР УРАЗА ТОТМЫЙ?

Юлчы, бик өлкән яшьтәге кеше, йөкле һәм бала имезүче хатыннар, хәез (күрем) һәм нифас (бала тапканнан соң кан килү) чорына кергән хатыннар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘБРИ ХӘБРИЕВ:

«БИТЛЕК КИЮДӘН МӘГЪНӘ КАЛМАДЫ»

Кеше көлмичә яши аламы? Юмор – ул дәвалау чарасымы? Татар нәрсәдән көләргә ярата һәм нәрсәдән көлә белми? 1 апрель – Көлке көнендә без юмор остасы Әбри ХӘБРИЕВ белән сөйләштек.

:: Ни хәл?

– Аллага шөкер, бар да тәртиптә. Әкренләп концертлар сезонын ачып җибәрдек. Һәрвакыттагыча, «Татар радиосы»ндагы иртәнге эфирда гөрлибез. Өй белән радио арасында һәм вак-төяк эшләр белән чабып тик йөрим.

:: Моннан ун еллап элек басылган бер интервьюда сез: «Татар үз-үзеннән көлә белми, һәм бу – безнең кимчелегебез», – дигәнсез. Инде шактый вакыт узган, ни дә булса үзгәрдеме?

– Үлем җәзасын тар даирәдә, әйтик, үтерү, террористик җинаятьләр, этник һәм дини нигездәге геноцид очракларында кулланырга мөмкиндер. Минем уйлавымча, террорчылар, атыш оештыручылар, көчләүчеләрне үлем җәзасы гына туктатып кала алмас, әмма андый җинаятьләр санын киметер иде, – дигән фикердә белгеч.

Шагыйрь Рифат Җамалның исә үлем җәзасына карашы башка. Аны кайтаруларын да хуплый ул.

– Кеше гомеренең кадере бетте, җинаятьләр саны күбәйде чөнки. Һичшиксез, үлем җәзасына хөкем ителердәй җинаятьләр бар. Хәтта «мин сине үтерәм, миңа моның өчен төрмә генә яный» дип әйтеп үтерә башладылар. Махсус әзерләнеп, уйлап, кеше үтергән затны нормаль кешегә санамыйм. Мәсәлән, балаларны көчләүчеләр, үтерүчеләр. Күбесе – элек утырып чыккан кешеләр. Чыга да яңадан шул эшенә тотына, – ди ул. – Билгеле, үлем җәзасын бик җентекләп тикшереп, 100 процент дәлилләр булганда гына кулланырга мөмкин. Җинаять бар икән, җәзасы да тәңгәл булсын. Шундый уем да бар: мондый җинаятьчеләрне җыеп, утрауга урнаштырырга кирәк. Шунда теләсә нишләсеннәр. Сакчы да, администратор да кирәкми. Бары тик җәмгыятькә генә чыкмасыннар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ҮЛЕМ ҖӘЗАСЫН КУЛЛАНУЧЫ ИЛЛӘР БИШЛЕГЕ

✷**Кытай.** Ришвәтчелек, наркотик сату һәм браконьерлык өчен җәза каралган.
✷**Иран.** Шпионаж, кеше үтерү, наркотик сату, көчләү, фахишәлек, алкоголизм, җенси җинаятьләр, хыянәт, ришвәтчелек белән шөгыльләнүчеләргә карата киң кулланыла.
✷**Согуд Гарәбстаны.** Кеше үтергән һәм наркотик саткан өчен декапитация (шәригать таләпләренә туры китереп, кылыч белән башны кисү) кулланыла.
✷**Гыйрак.** Күпчелек очракта террорчылык, террористик оешмаларга ярдәм иткән өчен асып үтерү каралган.
✷**Вьетнам.** Үлем җәзасын дәүләт иминлегенә, граждандык хокукларына, гаиләгә, сәламәтлек һәм намуска каршы җинаятьләргә карата кулланалар. Чарасы – инъекция.

САН

«SuperJob» хезмәте оештырган сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россиядә үлем җәзасын кайтаруны халыкның 43 проценты хуплый. 37 проценты каршы килүен әйткән, 20 проценты җавап бирүдән баш тарткан.
Моннан 13 ел элек үлем җәзасына кагылышлы сораштыру катнашучыларының 56 проценты «хуплыйм», 25 проценты «каршы» дип җавап биргән.

НАЛАСАНЫ БӘХЕТ БАСА

Әй, Наласа, Наласа ла, Наласаны су баса... Юк, язгы ташу вакытында авылны су басмый, басканы да юк, җырда гына шулай икән. Элеккеге миллионер колхозда бүген дә халык муллыкка омтылып, бәрәкәткә ирешеп яши. Китмиләр, киресенчә, монда кайталар. Язгы кояшлы көннәрнең берсендә Арча районының Наласа авылын күреп кайтырга булдык.

Гамьле яшьләр

«Соңгы сигез елда, яшьләрне авылда калдыру өчен, 23 йорт төзеп чыктык, тагын төзибез әле». Авыл җирлеге башлыгы Илфира Шакированың горурланып әйткән сүзләре бу. Наласада 230дан артык хуҗалыкта 729 кеше яши. Сөбханалла, 30га якын эшмәкәр үз эшен ачкан. Кемдер терлекчелек буенча мини-ферма булдырган, кемдер тимер, агач эше, умартачылык белән шөгыльләнә. Машина ремонтлату өчен дә ерак барасы түгел, остаханә үзләрендә генә. Монда кеше чакыртып эшләтмиләр, бар нәрсәгә үзләре ябышалар.

Авыл башында ферма күренә. Буш түгел, асрарга сыерлары да, эшләргә кешеләре дә бар. Урамнары төзек, асфальт җәелгән. Моңа кадәр төзелгәннәре арасында ике катлы яңа йортлары да ишәеп килә. Кибете, клубы, мәктәбе, бакчасы, фельдшер-акушерлык пункты, лимонад цехлары бар. Анысында дүрт кеше хезмәт куя. Тәмле су гына түгел, токмач, кесәл дә ясыйлар. Авыл чишмәсенең суы чисталыгы буенча беренче урында икән. Лабораториядә махсус тикшерткәннәр. Шуңа күрә Арча халкы Наласа чишмәсенә йөри дә инде.

Авылның киләчәген чамалар өчен, балалар бакчасына барып карарга кирәк. Без шулай иттек тә. Ике ел элек ачылган бакчаны монда Президент бүләге дип йөртәләр. Рөстәм Миңнеханов төзелеш барышын үзе күзәтеп киткән.

– Бүген 47 бала йөри. Соңгы вакытта иң зур күрсәткеч бу. Барысы да – үзебезнекеләр. Егерме ел элек эшкә килгәндә, 17 сабый гына иде. Бакча иске, кечкенә, балалар сыймый. Бәйрәмнәр уздырганда, клубка урындыклар ташып азапландык. Хәзер бик рәхәт. Быел 11 бала 1 нче сыйныфка бара. Чиратта ун бала тора. Гаиләләрдә 2–3әр бала үсә. Яшьләр булмаса, бакча, мәктәпләрдә балалар булмас иде, – ди бакча мөдире Гөлназ Абдрахманова.

Телең тәмле булса...

Авылның бүгенге тормышында җирлек башлыгы Илфира Шакированың да роле зур. Укытучы булып эшләгән ул, башлык вазыйфасына килүенә – ун ел. Илфира ханымга монда да укытучы булырга туры килә. Бик зирәк булганда гына сине тыңлаячаклар һәм ишетәчәкләр.

– Соңгы елларда Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы бик күп программалар булдырды. Субсидия биреп, йортлар салу да бар. Без аларның барысыннан да файдаланабыз. «Игенче» агрофирмасы да тотрыклы. 35 яшькә кадәрге яшьләр агрофирмада эшли, балалары бар икән, кире кайтарылмый торган субсидия яки миллион сумнан артык акча бирелде. Ел саен икешәр субсидия отып бардык. Агрофирмада түләү бик әйбәт. Белгеч булып кайтучы биш кешегә йорт салдык. Бишесенә бушлай җир бирдек. Салымны да үзебез түлибез. Тагын йорт салу программасында катнашырга исәп. Субсидияле 17 йорт салдык, бүген унсигезенчесен тапшырдык, тагын өчәү чиратта тора, – ди Илфира Шакирова.

Шул ук вакытта, егетләрен дә, эшчән, тәвәккәл дип мактап куя. Ялгыз яшәүче әби-бабайларны да онытмый башлык. Читтә яшәүче оныкларның да күңел кылларын чиртә белә. Алар, төп нигезгә кайтып, йортлар сала башлаган. «Бүген теләсә кая йөреп эшләп була бит. Иң мөһиме: нигезләр таркалмый», – дип куана ул. Кадрларны үстерү буенча мәктәп белән элемтәдә тора. Быел максатчан программа буенча аграр көллияткә баручы егетләр, шәфкать туташы булырга теләгән кызлар да бар. Алар да, укып бетергәч, авылга кайтабыз, дип торалар икән.

Наласа – керәшеннәргә дә бай авыл. Әхәт батыр Закиров истәлегенә җирлектә көрәш ярышлары уздырыла. Утызлап көрәшче егетләре бар икән.

Безгә бар да кызык

Авыл урамнарыннан атлыйбыз. Үзебезчә, үзенчәлекләрне барларга тырышабыз. Фотохәбәрчебез Илдар Мөхәммәтҗанов бакчага төртеп күрсәтә. Карлы бакчада ак халат киеп, кемнәр йөри? Умартачылар икән. Безнең бит аларны җәен генә күргән бар. Шуңа күрә, бу кадрны тиз генә төшереп, умартачы Рамил Исмәгыйлевның капкасын ачып керәбез. Бу эш белән 15 еллап шөгыльләнәләр.

– Кортларның йокыдан уянып, ялдан чыга торган вакыты бит. Кичә үк чыгарган идек, берничәсе тавышлангач, ашарга бирдек. Чагалар, усаллар, – ди Рамил.

– Шикәр комына кытлык бит хәзер. Сезнең бизнеска зыян китермиме? – дип сүзгә кушылды фотохәбәрчебез.

– Шикәр ашатмыйм. Ширбәт бары көз көне генә кирәк, язын кирәкми, – ди умартачы.

Авылда без, журналистлар, рухи азык эзлибез инде, ә куянга нәрсә калган? Балалар бакчасы янышнан күз ачып йомганчы озынколак узып китте. Сабыйлар күрсә, исләре китәр иде инде. Нәрсәгә килсен, алмагач кимерергә килә икән. «Эзләре күренә, тик үзләре юк. Видеокамерадан карагач, куян икәнен белдек», – дип елмайды бакча мөдире Гөлназ.

Шәһәрдән артыграк та әле...

Авылга күченеп кайту Төхвәтуллиннар гаиләсен тагын да түгәрәгрәк, бәхетлерәк иткән. Монда туып-үсмәсәләр дә, Ләйсән белән Рөстәм – Наласада үз кеше. Биш-алты ел элек күченеп килгәннәр. Дүрт кыз бала тәрбиялиләр.

– Башта иске йорт сатып алдык. Капка ясатып, сарай салдык. Иске йортта яшәп булмый дип, яңасының нигезен булдырдык. Менә тиздән яңа йортка күчәргә җыенабыз, – ди 35 яшьлек Рөстәм.

Шәһәрдә яшәсәләр дә, авылга тарткан аларның күңелләре. Хезмәт хакларын азрак түли башлагач, Арчага кайтырга тәвәккәлләгәннәр. Казан дәүләт энергетика университетын тәмамлаган Рөстәмгә үз белгечлеге буенча эш тә табылган. Ләйсән – Арча районының Урта Бирәзә авылы кызы. «Үз йортыбызны булдыру хыялы бар иде. Хатыным агрофирмага пешекче булып урнашты. Яшь гаиләләргә бирелә торган субсидия алып, йорт төзедек. Монда килгәнгә үкенмибез..

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ипилек-чәйлек...

– 2010 елда такта ярдыру цехы ачтык. Акчасы ипи-чәйгә җитә. Урындыгын да, башкасын да ясыйм. Тик агач эшләнмәләренә ихтыяҗ зур түгел, кеше кибеттән арзангарак сатып ала. Әле менә заказга бер сыерчык оясы ясадым. Бәясе – 500 сум. Балта эшенә хирыслык кайдан килгәнен әйтә алмыйм. Иң беренче ясаганым урындык булды, – ди Илшат Шәмсетдинов.

Моңа кадәр Илшат колхозда механизатор, комбайнчы булып эшләгән. Умарта, сыер асрап, балын, сөтен сата. Эшләгән кешегә эш бетми, ди. Иренмәсәң, тормыш бара, тик рәхәтләнеп йоклап ятып булмый.

Рәдиф Әхмәдуллин да умартачы булып чыкты, балавыз коясе сыгынтысы, бал икмәге ясый. «Төнәтмәне кортларның личинкаларын үрчетеп әзерлим. Организм өчен бик файдалы, шифасын күрәбез. Быел менә 36 нчы умартачылык сезонын башлыйм, – ди элек зоотехник булып эшләгән 75 яшьлек Рәдиф абый. – Бу эшкә безне «Октябрь» колхозы рәисе Мирзаян Вахитов өйрәтте. Ул эшләгән вакытта авылда 27 хуҗалык корт асрады. Авыл халкы яшелчә, җиләк-җимеш үстерә белми иде, рәис өйрәтте».

Орденлы апалар

Колхозның орденлы апалары белән дә сөйләштек. Гөлфия апа Хөсәенова шушы авылда туып, гомерен терлекчелеккә багышлаган. 20 еллап сыер сауган, аннан ясалма орлыкландыручылыкка укыган.

– Сыерларыма кушаматлар тага идем. Карлыгач, Сандугач дип йөрттем иң яратка681ннарын. Сыерлар да бозаулаттым. Үрчем әйбәт була иде. «Без сөт эчертә алмыйбыз, син ничек эчертәсең?» – дип аптырый иде хезмәттәшләрем. «Кил, җаным», – диюгә, бозаулар тизрәк чиләккә башларын тыгалар иде. Колхоз рәисе Казанга укырга җибәрде. Башта карышсам да, риза булдым. Дөресрәге, әни үгетләде. Ясалма орлыкландыру эшен бик яратып башкардым, – ди оптимист рухлы 73 яшьлек Гөлфия апа.

Бер тапкыр сыеры «шпагат»ка утырган була, шуны торгызам дип егылып, умыртка баганасын сындырган. Ферма тормышында әнә шундый вакыйгалар да була. Тормышы да гыйбрәтле Гөлфия апаның. Өч айлык көмәнле чагында ире үлеп китә. Бала хакына дип кияүгә дә чыкмый. Бүген бердәнбер улы Илнур, килене Римма тәрбиясендә яши.

– Киленем бик әйбәт, 20 ел торабыз. Бер тапкыр да сүзгә килгән юк. Икебез бер дулкында. Үзенә дә: «Мин сине үз әниеңнән дә катырак яратам», – дим. Оныкларым бик акыллы. Шифаханәгә дә барасы килми, үз өемдә җәннәт, – ди ул. – Кызым, һәр җирдә дә ярату кирәк. Авылны, эшемне гомер буе яратып яшәдем. Наласа көннән-көн матурая. Без үзгәрешләрне күреп, сөенәбез. Өлкәннәргә алмашка тырыш, акыллы яшьләр килә. Без салган орлыклар шытып, җимешләрен бирә.

Сәрия МИФТАХОВА

АЛТЫ БАЛАЛЫ ГАИЛӘ БАШЛЫГЫ:

«ЙОРТ САЛАСЫ ИДЕ...»

Арча районының Иске Җөлби авылында яшәүче алты балалы Шерматовлар гаиләсе урамда калган. Үзләре өйдә юк чагында ут чыгып, йортлары кара күмергә әйләнгән. Бүген алар күршедә яшәүче әбиләренә күченгән. Әмма анда да озакка калып булмый. Биредә әбиләренең оныгы белән ире яши икән.

– Ул көнне ярый әле өйдә кеше булмаган. Янгын көндезге сәгать унда чыккан. Йоклаган чакта ут капкан булса, нишләр идек, – дип сөйли кызлары Гөлшат. – Минем олы абыем армиядә. Аны 2 декабрь көнне озаттык. Икенче абыем Казанда укый. Мин дә Казанда белем алам. Авылда 5 нче һәм 3 нче сыйныфта укучы һәм 6 яшьлек туганнарым бар. Атна азагында гел бергә җыела идек. Өебез көлгә әйләнү барыбыз өчен дә авыр булды. Әти белән әни әле дә шок хәлендә.

Гөлшатның әнисе Гөлүсә ханым – сыер савучы, әтиләре Юлдаш Казанга йөреп эшли. Шерматовларның өйләре авылдан читтәрәк урнашкан. Шуңа да ут капканын күрүче булмаган. Каршы як урамдагы күршеләре дөрләп яна башлагач кына утны күреп алган. Алар янгын сүндерү машинасы чакыртса да, йортны саклап кала алмаганнар. Күршеләр дә ярдәмгә ашыккан. Әмма, ни кызганыч, өйдән берни алып чыгып булмаган. Барлык документлары, кием-салымнары көлгә әйләнгән.

Гөлшатның әтисе Юлдаш абый белән дә сөйләштек. Янгыннан соң әле дә аңга килеп бетеп булмый, ди.

– Бу хәл безне тетрәндерде. Башта югалып та калдык. Авыл кешеләре ярдәмчел инде. Кем генә булышмый. Ризыклар да китерәләр, кием-салымнар да. Үзебездә ана капиталы сертификатыбыз бар. Район башлыгы да, ярдәм итәрбез, дип ышандырды. Озакка сузмыйча гына нигезебездә яңадан йорт салып чыгарга исәпләп торабыз, – ди ул.

Юлдаш абый әйтүенчә, өйне иминиятләштермәгәннәр. Гаилә ишле булгач, эшләгән акчабыз тормыш итәргә генә җитеп барды, ди ул.

Иске Җөлби авылы Утар-Аты авылы җирлегенә керә. Җирлек башлыгы Альбина Мөхәммәтгалиева сүзләренә караганда, Шерматовларга алар йорт та эзләп караган.

– Авылда иске өйләр күп. Берәрсен сатмаслармы дигән идек. Әмма барысы да җәй көне кайтып торалар икән. Башка буш өй тапмадык. Кулдан килгәннең барысын да эшлибез инде. Ул гаилә янына көн дә киләм. Кечкенә балалар кызганыч. Киемнәр алып килгәч, бик сөенәләр балакайларым. Без аларның үзләре белән сөйләшеп, подрядчы оешма аша йорт салдырырга дигән фикергә килдек, – ди Альбина Мөхәммәтгалиева.

Бу гаилә берничек тә үзләре генә йорт салып чыга алмый. Шуңа аларга ярдәм кирәк.

▸ *Кызлары Шерматова Гөлшат Юлдаш кызы исемендәге Саклык банкы картасы номеры:* ***4279 3806 3154 2356****;*
«Тинькофф» банкы картасы номеры: ***5536 9140 3051 5476****. Карталар 89053718589 телефон номерына беркетелгән.*
▸ *Әниләре Гөлүсә исемендәге «Ак Барс» банкы картасы номеры:* ***4000 7934 7933 4684****. Ул 89656000432 телефон номерына беркетелгән.*

Теләк булса, җае чыга

Вероника Лазарева белән безне «Татарстан энҗесе» бәйгесе таныштырды. Туганда кул һәм аяк чуклары булмаган кыз рәсем ясый, җырлый, көйләр яза. Аңа карап сокланмаган кеше юк. Күпләргә үрнәк Вероника. Бик күп бәйгеләрдә, әйтик «Россиянең бөек кешеләре» һәм «Татарстан энҗесе» республика бәйгесендә җиңү яулаган кыз ул.

Верониканы тудырганда, әнисенә акушер: «Кызыгыз авыру, озак яшәмәячәк», – ди. Яшь ана, бу сүздән куркып, баладан баш тарта. Шулай итеп, Вероника ятимнәр йортына эләгә. Кыз анда күп нәрсәгә өйрәнә. Кызганып торучы булмый. Хәер, Вероника үзе дә кызганганнарын яратмый.

– Миңа анда рәхәт булмады. Протезлар белән йөрдем. Аяк киемен кию дә авыр иде. Әмма тырыштым. 5 яшемдә инде җырлап йөри башладым, – дип искә ала ул.

Кызның бик тә гаиләле буласы килә. Бервакыт Яңа ел бәйрәме алдыннан тәрбияче киңәше белән Кыш бабайга хат яза. Шул ук елны могҗиза була. 7 ел буе баласын читтән генә күзәткән Татьянага икенче ире баланы өйгә алып кайтырга тәкъдим итә. Шулай итеп Верониканы килеп алалар. Яңа әтисе үз фамилиясен бирә.

– Өй тормышына өйрәнү җиңел булмады. Мин ут сүндереп йокларга курка идем. Әнием янымда булгач, курыкмый башладым. Өйдә әкренләп кайбер эшләргә өйрәндем. Кем өчендер бик гади эшләр булса, миңа алар бик катлаулы тоела иде. Ашарга җылыта белүемә, чәй ясарга өйрәнүемә бик сөенделәр, – ди Вероника.

Вероника бик матур җырлый. Хәтта синтезаторда уйнарга да өйрәнгән. Ул моның өчен укытучыларына рәхмәтле.

– Мин үҗәт. Укытучым кушкан көйне өйрәнмичә йокларга да ятмый идем. Миңа синтезаторда уйнау бик ошый, – ди ул. – «Татарстан энҗесе»ндә катнашуым миңа бәхет китерде.

Шунда күреп, популяр җырчы Анна Седокова мине үз студиясенә җыр яздырырга чакырды. Бик уңайлы коляска бүләк итте. Без әле дә аралашып торабыз.

Вероника үзен төрле яклап сыный. Кыю йөрәкле кыз ул. Парашютта да сикергән.

Хәзер ул үзе кебекләрне авырлыклар алдында югалып калмыйча яшәргә өйрәтә. Элек Чаллыда яшәсә, күптән түгел Казанга күченгәннәр. Монда инде кыз өчен мөмкинлекләр күбрәк, әлбәттә.

– Җырлар язам. Кешеләр белән аралашам. Алар минем яннан бик сөенеп китә. Димәк, безнең аралашудан җаннарына тынычлык табалар. Ә миңа шул кирәк. Башкаларның елмаюы яшәргә көч бирә, – ди ул. – Кул-аяклар булмаса да, максатыңа ирешеп була. Теләк кирәк. Ә мин моны яхшы беләм.

Автор фотосы

Йөрәк белән сөйләшә

Кукмара районының Өркеш авылында гомер итүче 91 яшьлек Мәгъмүрә Хәбибуллина сөйләшми һәм ишетми торган кызларын берсүзсез аңлый. Аның ике баласы да ишетү сәләтеннән мәхрүм. Тумыштан авыру булмый алар, язмыш шулай куша. Бер кызын яшен суга, икенчесе мунчадан авырып чыга. Хәер, ул апалар үзләрен кимчелекле итеп сизми. Киресенчә, тормышны яратып, башкаларга яхшылык эшләп яши алар.

– Тормышым җиңел булмады. Ачлык кичергән буын без. Бик тилмереп үстек. Ирем Хаммат яхшы кеше иде. Аңа кияүгә чыгып, бик бәхетле яшәдем. Бер-бер артлы биш баланы туды. Игезәк баламның берсе тугач та вафат булды. Дүрт балабызга сөенеп, матур яшәдек, – ди ул. – Тик ачы хәсрәтләр алда көткән икән. Олы кызым Вәсиләне кечкенә чагында яшен сукты. Исән калса да, сөйләшми һәм ишетми торганга әйләнде. Берминди табибка да күрсәтмәдек. Кече кызым Гөлүсәне тән температурасы югары вакытта мунчага керткәнбез. Ул шуннан соң ишетми һәм сөйләшми башлады.

Кызларны Алабуга шәһәрендәге махсус мәктәпкә укырга җибәрәләр. Ул чакта телефоннар да юк. Кайтып йөрүләр дә еш булмый. Әниләре хәзер шуларын исенә төшерә.

– Мин кызларыма берминди тәрбия бирә алмадым. Аларны нинди укытучылар укытып, нинди тәрбиячеләр тәрбияләде икән?! Рәхмәт аларга. Эшкә дә өйрәткәннәр. Укыйяза да беләләр. Кулларыннан килмәгән эш юк. Шулкадәр чисталыкны яраталар. Бер эштән дә куркып тормыйлар, – ди Мәгъмүрә әби.

Кызлар Алабугада укып кайткач, Казанга китеп эшкә урнаша. Сөйләшә алмау комачау итми аларга. Ишарәләр белән аңлашырга өйрәнәләр. Казанда исә үзләре кебекләр белән дуслашалар. Әнә шулай итеп, тормышлары җайланып китә.

Вәсилә апа вертолет заводына эшкә урнаша. Шунда ул бер ир-ат белән таныша. Яшьләр гаилә кора. Аларның кызлары туа. Тик ир белән хатын бергә озак яши алмый, аерылыша. Кызчыкны Вәсилә апа белән сеңлесе үстерә.

– Мин әбиемә дә бик рәхмәтле. Әнинең бертуганнары Зәкия апам белән Зиннур абыем мине үз балаларыдай якын иттеләр. Әтисез икәнемне сизмәдем дә. Бабам бар җылысын биреп, кадерләп торды, – ди Алинә.

Язмыш җилләре алар ишегем тагын шакый. 2002 елда Хаммат абый үлеп китә. Озак та үтми, Зәкия исемле кызында тамак яман чире ачыклана. Табиблар операция ясый. Алдан ук кисәтеп куялар – сөйләшә алмаячак. Мәгъмүрә әбинең өченче баласы да сөйләшүдән мәхрүм кала. Зәкия апаның гомере озын булмый. Бер ел эчендә, 47 яшен тутырырга 10 көн кала, ул өч баласын ятим итеп, мәңгелеккә китеп бара.

– Яшәр өчен ничек көч табыйм икән? – дигәнем күп булды. Бала югалту ачысын үзе кичергән кеше генә аңлый. Бик авыр булды. Әле дә йөрәк яраларым сыкрап тора, – ди Мәгъмүрә әби.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ПРЕМИЯ ЯРМИНКӘСЕ

Бер караганда ул матди ярдәм кебек бирелүдән туктарга тиеш иде. Ник дигәндә, соңгы елларда Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән әдәби бәйгеләр узды. Талантлы язучыга матди ярдәм бит инде бу. Икенче яктан... Язучыларга дәүләт игътибары көчәйсә дә, Тукай премиясе мәсьәләсендә берни дә үзгәрмәде. Киресенчә, вакланды дигән сүзләр ешайды гына. Моңа тарихта беренче тапкыр исемлеккә егермегә якын дәгъва кылучы кертелү дә сәбәпчедер.

Кандидатларның күп булуы әйбәт. Ул – әдәбият-сәнгатьнең киң һәм колачлы булуына дәлил. Режиссер, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе комиссиясе әгъзасы Илдар Ягъфәров әнә шул фикердә. Шул ук вакытта ул аның масаючылар ярминкәсенә әверелүен дә яшерми:

– Исемлектә 19 кандидат булу, бер караганда, гаҗәп түгел, чөнки әдәбият-сәнгатьтә талантлы кешеләр күп. Һәм алар – төрлесе төрле өлкәдән, кемнедер төшереп калдырырга, кайсындыр алга чыгарырга бик авыр. Шәхсән миңа исемлеккә талантлы фотографның да, тарихчы Фаяз Хуҗинның да керүе кызыклы. Флера Гыйззәтуллина да премиягә лаек. Үз вакытында алмаган икән, нишлисең инде.

Быел 19 кеше турында матбугатта бер ай сөйләячәкләр, аларның әсәрләренә кызыксыну бермә-бер артачак, бу – иҗат кешесе өчен үзенә күрә реклама да. Дөрес, икенче этап каты, хәтта «канлы» булачак. Шулкадәр кешедән күп дигәндә өчне калдырырга кирәк була бит. Кемнәр үтәр – бу хакта бөтенләй әйтеп булмый.

Тукай исемен йөрткән бүләкнең дәрәҗәсенә килгәндә, бу җәһәттән уйланырга җирлек бар. Син матди ярдәм бүлешүгә кайтып кала дисең, мин аны «масаю ярминкәсе – ярмарка тщеславия» дип атыйм. Медаль тагарга шулкадәр атлыгып тору, ә инде максатына ирешкәч, эреп юкка чыгу – моны ярминкә дими, тагын ни дисең?

> Премия үзе шәхесне эзләп табарга тиеш, киресенчә түгел. Аның өчен аны яшерен юл белән сайлап куярга кирәктер. Бу очракта иҗатчылар ул премиягә тәкъдим ителүләрен белмичә дә кала. Ә безнең система, кешеләрнең үз-үзен тәкъдим итүе белән үк, ялгыш юлга кереп китә. Бер кеше үзен 3 тапкыр, 5 тапкыр премиягә куя. Чөнки ул, теге алды бит әле, мин дә алырга тиеш, дигән фикер белән эш йөртә. Әсәрләрнең тиранлеге исә елдан-ел саега.

Татар мәдәнияте елдан-ел ком сарае сыман ишелә дә ишелә. Менә бу күренеш белән нишләргә? Төпкә тәгәрәүне ничек туктатырга? Шул хакта уйланасы иде. Бу җәһәттән тәрҗемә эше ярдәм итә ала. Әдәбият мәйданы тарайды, миңа калса. Татарча яхшы роман туган икән, аны кичекмәстән русчага һәм башка телләргә тәрҗемә итәргә кирәк. Гүзәл Яхина романнары ни өчен популяр? Чөнки ул рус телендә яза, бездә исә русча укучы татарлар бихисап. «Город Брежнев»ны (Шамил Идиятуллин) да русча булганга укучылар күп. Шуннан тираж үсеп китә һәм ул әсәрләр грандиоз дигән миф туа. Татарча иҗат итүче көчле язучылар бик күп. Тәрҗемә эше тукталганга, алар киң катлау укучыга чыга алмый ята.

Галим, әдәби тәнкыйтьче Миләүшә Хәбетдинова да, Тукай премиясе өстәмә керем чыганагына әйләнде, дигән фикердә. Аныңча, дәүләт премиясен татар халкына хезмәт иткән милли әсәрләргә бирергә кирәк:

– Тукай премиясе керем артыннан кууга әйләнеп бара. Миңа калса, кешеләр аның гомуми принципларын, әһәмиятен аңлап бетермиләр. Ул – матди премия түгел. Ул – рухи яктан татар халкының тормышында зур урын алган бүләк. Мин монда негатив тенденция күрәм. Премия турында сүз чыкса, нишләп яшьләргә бирмәскә, дип әйтүчеләр табыла. Яки нишләп бу әдәби премияне рәссамнарга бирәләр, диләр. Ә бит Тукай премиясе – дәүләт премиясе. Димәк, әлеге премиягә лаек дип табылган әсәр татар халкына хезмәт итәргә тиеш. Бездә исә, менә рәссам яки язучы – аның юбилее, Тукай премиясенә тәкъдим итәргә кирәк, диләр. Әчтәлегенә әллә ни әһәмият бирелми. Элек Тукай циклын иҗат итәләр, милли темаларга язалар иде. Хәзер бу бетте. Бу җәһәттән хәзерге кандидатлар арасыннан, профессиональлек ягыннан да, әсәрләренең тирәнлеге, миллилеге ягыннан да шагыйрә Флера Гыйззәтуллина белән тарихчы Фаяз Хуҗинны гына премиягә лаек дип әйтергә була.

Язучы Зиннур Мансуров премия нигезләмәсендә бар да ачык язылган, аны үтәргә генә кирәк дип исәпли:

– Бу – 1958 елдан бирле бирелә торган дәүләт премиясе. Аның нигезләмәсендә бу премия әдәбият-сәнгать өлкәсендә халык тарафыннан зур казаныш буларак кабул ителгән әсәрләргә бирелә, дип, ассызыклап әйтелгән. Әмма соңгы 10–20 елда нигезләмәгә туры килеп бетмәгән әсәрләргә дә премия бирелә башлады. Әдәбият-сәнгать дигәндә без әдәбият, театр, музыка, рәсем, архитектура сәнгатьләрен күз алдына китерәбез. Ләкин соңгы берничә дистә елда бигрәк тә сәнгать өлкәсендә ориентирлар бозыла башлады. Икенчедән, премияне ваклау башланды. Бу фикер халыкта да бар һәм бу чыннан да шулай. Быел 19 кандидат тәкъдим ителгән. Минемчә, Тукай премиясенә дәгъва кылучылар исемлеген шулкадәр озын итеп күрсәтергә ярамый. Премия комиссиясенең кулында җиде иләк булырга һәм бу кандидатлар шушы иләкләр аша узарга тиеш. Шулай булганда матбугатта дилбегә буе исемлек дөнья күрмәс иде. Әйтик, дүрт театрны алыйк.

> Яшерен-батырын түгел, бүген театр сәнгате, драматургия зур кризис кичерә. Театрлардан тамашачы читләште, чөнки алар тәҗрибә үткәрү мәйданына әйләнде. Анда тамашачы турында уйлау бетте. Шуңа да аһ дип карарлык спектакльләр калмады. Шулай булса да, исемлектә театрлар күпчелекне тәшкил итә. Миңа бу бик тә, бик тә сәер булып тоела.

Фото сәнгате дә шик тудыра. Дөрес, чабата ясау да – үзенә күрә зур сәнгать. Әмма Тукай премиясенә дәгъва кылырлык сәнгатьме ул? Тарихчының дәгъва кылуы да аңлашылып бетми. Чөнки безнең фән һәм техника өлкәсендә дә дәүләт премиясе бар. Бу хезмәт шул премиягә 100 процент туры килә. Дәүләт, фән белән сәнгатьне аерып, ике премия булдырган икән инде, ул бүленешне сакларга кирәктер... Шулай итеп, бу зур исемлектә нигезләмәгә туры килеп бетми торган әсәрләр дә бар, кызганычка. Шуңа күрә аны халык сәерсенеп, борчылып кабул итте, күрәсең. Бу исә премиянең дәрәҗәсен күтәрүгә хезмәт итми.

Зиннур Мансуров белән премиянең бирелми калган вакытларын да искә алдык. 1961–1965 елларда ул төрле сәбәпләр аркасында бирелми тора. «Әлбәттә, мин бирелми калсын, дип әйтмим. Әмма бердәнбер дәүләт премиясе пачкалап та өләшенергә тиеш түгел. Шуңа күрә нигезләмә һәрвакыт үзәктә торырга тиеш. Бәяләнерлек әсәрләр дә юк түгел бит. Бер елда көчле әсәрләр күбрәк, икенче елда азрак булырга мөмкин. Табигатьтә дә уңыш шулай алына. Комиссиядә исә татар әсәрләрен укып бара торган чын мәгънәсендә профессионаллар, әдәбият-сәнгатьтән хәбәрдар булган кешеләр утырырга тиеш. Татарча белмәгән, татар әсәрләрен укымаган белгечләр әдәбият язмышын хәл итәргә тиеш түгелдер», – ди язучы.

Дәрәҗәсе яңартылырга тиеш. Шагыйрә, Кариев театры директоры Луиза Янсуар әнә шул фикердә:

– Миңа калса, Тукай премиясенең нигезләмәсен һәм һәрьяклап критерийларын да яңартырга кирәк. Бүген бәхәс ешкына шуңа кайтып кала: нәрсә өчен бирелә ул, аерым бер вакыйгага булган әсәр өченме, иҗатчының гомер буена тупланган иҗат багажы өченме, билгеле бер шәхеснең казанышлары өченме? Минемчә, иң беренче чиратта, әсәр яки әсәрләр циклы өчен бирелергә тиеш. Ул әсәрнең ни дәрәҗәдә резонанс уятканын да, халык тарафыннан кабул ителүен дә, сәнгати дәрәҗәсен дә исәпкә алу кирәк. Бәйсез рейтинглар, сораштырулар булдыру да комачау итмәс иде.

Тукай премиясенең дәрәҗәсе, аның статусы да яңартылырга тиеш, дип уйлыйм. Аның тирәсендә барган шау-шу әдәбият, мәдәният өлкәсендә кайнашкан кешеләр өчен генә түгел, ә һәркем өчен дә кызыклы булсын. Лауреатларны тәкъдим итү, сайлау этапларында мин, мәсәлән, кызыклы форматтагы очрашулар, дискуссияләр, видеоэңгәмәләр, подкастлар һ.б.лар күрергә теләр идем.

Әдипнең яки сәнгать әһеленең Тукай исемен йөрткән бүләккә омтылуы гаҗәп түгел инде ул. Тукай – татар кешесенә киңәшче дә, сердәш тә, илһам чыганагы да. Тукай белән илһамланыйм дип, Тукай музее сайтын ачам. Ул татарча сөйләшми икән бит. Тукай музееның төп теле – рус теле. Хикмәт үзебезне һаман да икенче сорт итеп кабул итүдәдер. Юкса, Тукай музее да, премиясе дә башка югарылыкта булыр иде. Ә хәзергә, әйдә, ярминкәгә!..

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Гүрбүз Азак

Мәрьямнең атлары

(романнан өзек)

< Дәвамы. Башы 25 март санында

3

Соңында ераклардан яктылык балкыды. Йокы белән йокысызлык арасында, бетә белмәгән төн киткәндә караңгылык эреде. Һәр тараф бер төрле дымланып көмешләнде. Шул вакытта без аякка бастык. Атларны арба янына кудым. Аклым акрын бул дигәндә, күңелем ашыктыра иде.

– Хатын, син әзерме?

– Әзер, Гомәр. Аһ, Гомәр...

– Мәрьям, син?

Шул, минем җүләр кызым Актуган өстеннән, әмер биргән йөзбашы кебек, җавап бирде:

– Әйе, абзыкай!

Арбага утырып, кулыма дилбегәне алдым. Хатыным минем артта утыра, кайбер әйберләрне җайлап куйды. Дилбегә белән атлар сыртына суктым, тәвәккәллек белән ант биргәндәй:

– Киттек, бисмиллаһ, – дидем.

Авыр арбаның тимер тәгәрмәчләре хыртлап урыннарыннан кузгалды. Чайкалып барабыз. Кызу китү заманы түгел. Күчеп китүебезне чит колаклар ишетмәсен. Мәрьям алда бара. Артка карыйм, хатынымның иреннәре кыймылдый. Билгеле, дога кыла.

Еллар дәвамында безне туендырган, үстергән, аягыбызда нык тоткан басуга барган кебек идек. Әмма кайгылы йөз белән. Ике сүз әйтерлек көч юк. Зират кырыеннан узганда, әтием, әнием, кардәшләрем – барысы аякка басып, безне озатып калдылар төсле. Чыннан да шулай дип уйлыйм. Башым белән барысына аерым-аерым сәлам бирдем.

Авыр сулама, Гомәр... Күзләреңдә яшь күренмәсен. Сине ничек, җитди һәм сүзен белеп, үлчәп сөйләгән кеше буларак беләләр, шулай булып кал. Әгәр бер онытылып китсәң, бер еласаң, агалыгың таралып китәчәк. Елама. Кара, әнә теге өч агачны каберлеккә син утырткан идең. Җомга көннәре бирегә килеп, баш очларында «Фатиха» укыган егермедән артык кабернең ташлары, ул өч агач кебек түзем һәм нык булу вакыты. Кара, ул җүләр кыз, ятим кыз елыймы? Агалар еламас, Гомәр.

– Гомәр, артыбыздан өч-дүрт арба килә. Бездән алда баручылар да бар.

Хатыным дөрес сөйли иде. Димәк, кәрван шактый озынаячак. Әйбәт ишарә.

– Мәрьям, сиңа әйтәм, кызым! Бераз акрынрак бар!

– Ярый. Әмма Актуган тик тормый!

Шулайдыр. Актуган ялларын җилфердәтеп очарга ярата. Ул да Мәрьямгә охшаган куркусыз иде. Нәкъ инсан кебек, һәр сүзне аңлый торган ат. Хәтерлим, Мәрьям аты белән чапканда таулардан ташлар коела, җир урынныннан кучкән кебек тоела иде. Бу атны бары Мәрьям йөгәнли ала иде, гел сәерсенеп күзәттек. Әгәр кыз: «Шул-шул таба бар, шундагы өйләргә, бакчаларга бар», – дисә, ат аны тыңлап, ул әйткән тарафка китә иде. Кыз кушса, Актуган урталыкны җәһәннәмгә әйләндерер. Башта аптырадык, аннары ияләштек. Бу ат бу кыз өчен дөньяга килгән иде.

Манзараны ерактан күзәткәндә, зур галәм минеке булды. Нәкъ алдан килешенгән җирдә, бездән күпкә иртә килгән арбалар бер-бер артлы тезелгән. Бераздан тагын өч гаилә өстәлде. Яннарына киттем, үземнең арбаны иң алга чыгардым. Арбамнан төштем, башка ир-атлар да төште, һәркайсы белән аерымаерым сәламләштем. Егерме ике арба санадым. «Әйдәгез, бер җыелыйк!» – дидем. Бабайлар, ирләр тупланды. Бераз йокылы, аптырашкан, сорау тулы дымлы күзләрен төбәгән кардәшләремә карап, шулай дидем:

– Якташларым, туганнарым! Барыбыз да бу җирләрдә тудык, еладык, көлдек. Бабайларыбыз, әбиләребез, әти-әниләребез кебек... Язмышыбыз, әчәсе суыбыз шушында кадәр икән. Моннан соң яңа бер Ватан эзләячәкбез, башка чара юк. Без куркак түгел, качып китмибез. Башыбызга киләчәк кайгыларны, толлыкны, ялгызлыкны, үлемне, хатын-кызларның акылдан язуларын ташлап китәбез. Алдыбызда кыш, озын юллар... Һәр түмгәк артында, һәр көн кичендә безне кыенлыклар, аянычлы хәлләр сагалап торачак. Бәлки дә бик күп кан, яшь түгәрбез... Әмма ни генә булмасын, без Анадолуга барып җитәрбез!

Сүземнән бүленеп, тирә-якка кабат күз салдым. Курку-ашыгулар артык күп сизелмәде. Сәхәр җиле хәерле юл теләп, һәркайсыбызны сыйпап узды. Хатыннар, кызлар, балалар да арбаларыннан коелды, кызыксынып якынлаштылар. Дәвам иттем:

– Туган җирдән аерыла алмам, сәфәрне күтәрә алмам дип, ваз кичәргә теләгәннәр, соңрак түгел, хәзердән сөйләсен. Кире кайтып китә алалар. Бәлки аларга шулай хәерлерәктер, белмибез ки. Артык арбаларга утыру вакыты җитте. Озакламый көн яктырыр. Бөтен юл кирәк-яракларын, язганнарымны алдыгызмы?

Артык тавышланмый гына сөйләштек.

– Әйе, Гомәр.

– Ләгәннәр, самавырлар, су комганнары?

– Алдык.

– Ә мылтыклар? Азыклар? Сәнәкләр?

– Алар да әзер.

– Алайса, ни булыр, ни булмас, хәзердән хәләлләшик. Һәркайсыгызга хакларым мең кат хәләл булсын!

– Безнеке дә!

– Сәфәребез мөбарәк булсын, туганнар. Аллаһ безнең белән!

Бу юлы ныграк кычкырдылар:

– Безнең белән!

Халык арбаларына таба юнәлде.

Дөнья яктырып, юллар ап-ачык күренә башлады, тезгеннәрен тартып, атларыма эндәштем:

– Көн яктырып килә, кузгалыйк. Аллаһ аякларыгызга көч-дәрман бирсен. Бисмиллаһ!

Һәм...

Бик газаплы, яга торган, үлә-терелә сөрәләчәк юлыбыз башланды. Ун минуттан соң кызыбыз Мәрьямгә бакырдым:

– Мәрьям! Кәрванны ура! Артка таба бер кит, бер кил. Анда ни хәлләр бар, миңа хәбәр ит!

Нәкъ ул теләгән әмер иде. Яныбыздан җил кебек исте китте. Әйләнеп килде. Кабат кубып киткәндәй артка чапты. Бу юлы кире килгәндә ат арбасына якынлашты, кашлары җыерылган, үзе сөйләнә:

– Гомәр абзыкай! Ике арба шәһәргә кире китте. Озын юлны күтәрә алмыйбыз, дигәннәр, имеш. Авыру бабайлары, сабыйлары бар икән. Танышлары шулай әйтте.

– Ярый, кызым, Аллаһ шифасын бирсен.

Мәрьям янә алдыбызга чыкты.

Иртәнге кояш нурлары белән бергә киң, ташлы туфрак юлдан барабыз, арба тәгәрмәчләренең тыкыр-тыкыр киткәне, атларның акрын гына пошкырган тавышы ишетелеп тора. Бу – сәфәребезнең беренче көне. Китә алган кадәр ераккарак китүебез әйбәт. Өйләгә кадәр тукталмадык. Һичбер хөкүмәт кешесе, тикшерүче, сакчы, юлыбызга чыгып: «Кая барасыз?» – дип сорамады. Аңлашылды. Күчеп китүебезгә сөенәләр иде. Нигәме? Чөнки Казан шәһәренең артыкларыннан котылачаклар.

Ашыкмыйча бара идек. Кәрван барганда кайбер хатыннар арбалардан төшеп, көзнең соңгы үләннәрен туплап, кабат арбаларга кыенлыксыз җитешеп утыралар. Яшьләр хәтта өчәр-өчәр бүленеп, кәрванны урый-урый ярыштылар. Алга чыккан яшьләргә кул чапкан балалар, кызлар, абыйып егылганнарны күргәч, рәхәтләнеп көлештеләр. Әйтерсең, бу зур кәрван якындагы бер ярминкәгә юл тота иде. Яки дә ярминкәнең үзе.

Шатлыклы тавышлар дәвам итсен, сөенечләр бетмәсен дип теләп барам. Ниятемдә кәрванны икендедән соң бер яшел аланда туктату, ял итү, хәтта кичне шунда уздыру иде.

Мәрьям бик шомарды, әле алга чаба, юл тузанына күмелә, күренмәс була. Әле артка таба җилдерә. «Кайда син? Еракка китмә!» – дигәннәремне ишетми дә. Аһ, Мәрьям, Аһ... дип торганда, икенде вакытына якынлашып килгәндә, сул ягымда кинәт пәйда булды һәм бар көченә диярлек кычкырды:

– Абзый! Кәрванга тагын өч арба өстәлде. Егерме өч булдык!

Тагын җил алды! Актуганның болай да туктап торырга исәбе юк. Койрыгын өскә кабарткан, тоякларын күрсәтә-күрсәтә чаба.

Ара-тирә аерым-аерым да, төркем-төркем булып та яныбыздан узган авыл кешеләре очрады. Юлларда, басу кырыйларында электән ватылып калган арбалар, черегән тәгәрмәчләр, ташландык чардаклар күрдек. Бер авыл аша узганда бөтен халкы чыгып баскан, хатыннары, балалары юл буйларына тезелгәннәр иде. Исләре китеп безгә карыйлар. Мондый озын кәрван күргәннәре юк, билгеле. Аларга иелеп сәламнәр бирдек. Кайберләре безгә кул болгап калды.

Ахыры бар >

Укучыларыбыз иҗаты

Миләүшә ӘХМӘДУЛЛИНА

Кадим

Мин түгел, бер кадим,
Түгелмен ак галим...
Күрәшмим теш-тырнак,
Бик гади, күркәм зат...
Хөсеткә камил тар,
Кушканча Тәңрем бар.
Язмын көндәлек,
Шагыйрьлек миңа оят...

Илһамнар эзләмим,
Дөньялар гизәлмим...
Тик... күңел – пар канат,
Очыштан туялмый...
Хыялым төпсезлек,
Төсләре чиксезлек...
Мыскалмы, олугмы,
Кодрәтем тыялмый...

Йөрәгем кушканча,
Зиһенем куйганча –
Каршылык мул хәзер,
Иминлек – зур байлык...
Тәтеми һәрдаим
Сабырлык тәгаен...
Олпатлар юлында
Салынган тугайлык!

Булыйкчы бердәмле,
Татулык хуш тәмле, –
Калмыйкчы бер үзгә,
Нахактан җан бизә...
Сыктылап сыкрана,
Бәргәләп уфтана...
Кимермик бәгырьне,
Пәрәләр чак түзә...

Сынама, тәкъдир

Сынамале, тәкъдир, гелән мине,
Гөнаһларым әллә күпме соң...
Инде күгем аязадыр дисәм,
Кабат урап ала көзге моң...

Сынамале, тәкъдир, мин баш идем
Синең көчле сынау алымга...
Салкын карлы яңгырларың белән
Яшем түктем бүген алдыма...

Сынамале, тәкъдир, тезләндем бит,
Шуннан ары нидә өметем...
Бераз тезгенеңне тыеп торчы,
Язмышымнан бәхет мин көттем...

Сынамале, тәкъдир, мәтәлдермә,
Тын алырга бераз вакыт сал...
Күгелҗемле, зәңгәр галәмемнең
Гүзәллеген, диген, күреп кал...

Вөҗдан

Кеше булалмаган түбәнсетә,
Ә бит җиһан аннан нидер көтә...
Күккә элдем, диеп, әләмен –
Оныта ул бирер сәламен...

Моңа тиклем ник соң йокладың,
Кеше(!)легең данын тотмадың...
Горурлыгың үскәч югары,
Миһербаның кая югалды...

Әҗерләмә хәзер бар бәндә,
Башын иде кыйблаң бер мәлдә...
Аңга килер, йөрмәс саташып,
Мәлгуньнәрчә, сазда адашып...

Күзең ачсаң, таны чынлыкны,
Нәзакәтең талдай чыбыкмы...
Намусларың бары куыкмы,
Вөҗданнарың бәлкем сыныкмы...

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Дания нәзарәте

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.
Бер җиңүчегә Татарстан Дания нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:
«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында. 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә. Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

БРИГАДА
СТРОИТЕЛЕЙ ВЫПОЛНИТ ВСЕ ВИДЫ РАБОТ
Телефон: 89600509692

Реклама

КАРНИКА һәм КАРПАТКА токымлы бал кортлары семьясын сатам. 4 рамкалы, 2-3 кәрәзе – личинкалы, 1 кәрәзе – бал икмәге белән.
+7 96 55 99 88 67, +7 96 25 61 60 93
Пчелопакет Карника и Карпатка комплектация по 4 рамки 2-3 расплодом + 1 медаперговая
Реклама

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ЧАЙНВОРД

«ХУШ КИЛӘСЕҢ, РАМАЗАН!»



Нияз Бишбалта

1. Изге айда һәр көн ураза тоту гамәле.
2. Ураза тоту – тәннең ...е.
3. Ураза аенда укыла торган намаз.
4. Ифтарда авыз ачу өчен татлы җимеш.
5. Ураза тотучыга Аллаһ тарафыннан языла торган савап.
6. Ураза ае.
7. Ураза тоткан кеше ...ен тыя.
8. Ураза тотучының таң атканчы ашау вакыты.
9. Ураза тотканда тыелган нәрсә.
10. Изге айда иңгән Изге китап.
11. Тотачак ураза турындагы уй-теләк.
12. Гыйбадәт алдыннан юыну.
13. Уразаны, гыйбадәтне тырышып үтәү – Аллаһка ... кылу.
14. Намаз укыганда мөселманнар юнәлә торган як.
15. Ифтардан соң укыла торган намаз.
16. Намазга чакырып азан әйтелә торган биек корылма.
17. Ураза тотмаска рөхсәт ителгән кеше.

Җаваплар. 1. Фарыз **2.** Зәкят **3.** Таравих **4.** Хөрмә **5.** Әҗер **6.** Рамазан **7.** Нәфес **8.** Сәхәр **9.** Ризык **10.** Коръән **11.** Ният **12.** Таһарәт **13.** Тәкъвалык **14.** Кыйбла **15.** Ахшам **16.** Манара **17.** Авыру.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Казан шәһәре мэры Илсур Метшин үз вазыйфасына ничәнче елда керешә?
А) 2001;
Б) 2006;
В) 2010.

2 1550 елда яңа законнар җыентыгы эшләнә. Аның исеме...
А) «Троица»;
Б) «Кодекс куманикус»;
В) «Хөкем китабы» («Судебник»).

3 Император Николай IIнең идарә итү еллары.
А) 1894–1917;
Б) 1861;
В) 1881–1894.

4 «Конституция» сүзе латинчадан нәрсә дигәнне аңлата?
А) хокук;
Б) төзү, урнаштыру;
В) берләшү.

Җаваплар: 1) Б; 2) В; 3) А; 4) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 245

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+